**Фарсель Зыятдинов**

БЕЗНЕҢ ГОМЕР

Шигырьләр, әкият, поэмА

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2 Рос=Тат)-5
З82

**Зыятдинов Ф.С.**

Безнең гомер: Шигырьләр, әкият, поэма/
Фарсель Зыятдинов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 175 б.

ISBN 5-298-03906-5

Әлеге китапка авторның төрле елларда язылган шигырьләре, әкияте һәм поэмасы тупланды.

ISBN 5-298-03906-5

© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Зыятдинов Ф.С., 2006

## КАЙТУ

### ТАГЫН КИЛДЕ ЯЗЛАР...

Тагын килде язлар.
Илләр гизеп,
Сайрар кошлар кире кайттылар.
Сайрый берсе, сайрый талга кунып,
Кемнән безгә сәлам тапшыра?
И шатлана, сайрый, канатлана,
Кайткангамы туган ягына?
Ә сәламен меңнәр кабул итә,
Моңы меңнәр өчен агыла...
Дәртләнеп, ул канатланып шулай
Илләр аша сәлам тапшыра.
Кошларыбыз теле кешелекле,
Кошлар теле дәшә яхшыга.

### КУРАЙ

Әй, курай,
курай,
курай,
Бабам уйнаган курай.
Әткәм уйнаган курай.
Еллар үткәч, ник соң әле
Китеп югалдың болай?
Артык моңлы булгангамы?
Урау булды юлларың...
Еллар томаны артына,
Еллар томаны артына

Китеп күздән югалдың...
Күп нәрсәләр күңелләрдән
Вакытлы китеп тора.
Кайтырсың, дим,
Синнән башка
Ил күңеле китек тора.

*** * ***

Иделгә таянма, дисең,
Соң, кайларга таяныйм?
Кемнәр белән серләшим дә,
Кемгә карап юаныйм?

Идел бит ул үткәнебез,
Ул бит безнең киләчәк!
Оныкларга моңыбызны
Чал Идел җиткерәчәк.

Иделгә таянма, дисең,
Уеңны һич аңламыйм.
Иделгә дә таянмагач,
Кайларга соң таяныйм?!

*** * ***

Салынды сер бирмәс канатлар,
Зур төен төйнәлде күңелдә.
Давылмы, яңгырмы — ни булыр?
Болытлар куера күгемдә.
Куерсын...
Куерсын, ни булган?
Йөрәктә битараф көн туган.
Яшьнәгән, дөрләгән күңел гел
Бер мизгел эчендә булды көл.
Шул көлдән оешып авыр таш
Гәүдәмне каядыр сөйри күк.
Атлыймын гүя мин зираттан,
Каберләр риваять сөйли күк...
Чардуган.
Күрми ул кояшны,
Каплаган усакның башлары.
Сукмагым буена тезелгән
Хисләрнең чатнаган ташлары.
Чү! Аргы ягында зиратның
Чын тормыш гөр килә түгелме?
Чыгыгыз, әй, үлмәс хисләрем,
Калдырып көлләнгән күңелне.
Чыгыгыз, әй, олы хисләрем,
Кабызып сүрелгән күңелне!

## КАЙТУ

Идел-йортым кат-кат чайкалганда,
Сибелгәнбез бөтен дөньяга.
Бүленешеп гомер итәрбез дип,
Ул чагында кем соң уйлаган?

Бүленгәнне бүре ашаганын
Төшенсәк тә, соңлап төшендек.

Идел-йорттан һаман ераккарак —
Аю урманына күчендек...

Аерылганны аю таптаганны
Аңласак та, бик соң аңлаштык.
Җанын саклап калыр өчен күпләр
Маңкорт булып җирдә җайлашты —
Аю табанына ябышты.

Бүленгәнне бүре эләктерде,
Аерылганны аю таптады...
Изге сукмакларда туфрак булдык,
Ә туфракны үлән каплады.

Тапталсак та, бер горурлык хисе
Сүнми калган күңел түрендә:
Сынауларда сынмас Ватаным бар —
Туып килә ал таң күгендә.

Кыр казлары кебек каңгылдашып
Кайта татар изге иленә.
Тамыр төпкелләре тарта аны,
Геннар тарта Болгар җиренә.

*1994*

*** * ***

Бар нәрсә тартыла яктыга —
Юрыйбыз без моны яхшыга.
Һәр гамәл булмый тик түгәрәк.
Гомере бер көнлек күбәләк
Туктамый гел утка тартыла,
Янса да, керә ул ялкынга.

Уйласаң, батырлык үрнәге
Күбәләк — батырның өрәге.

*1995*

## БИК АЗ КАЛГАН ИДЕ ЯЗГА ДА...

*Г.Тукайга*

Әче җилләр,
Кар-бураннар куркытмады,
Гашыйк идең туган җиреңә...
Илләр сыкрап,
Җилләр елаганда,
Ышандың син
Бәхет тулы язның килеренә.
Шул чакта ук
Күңелләргә гөлләр чәчтең,
Чәчәк атсын, диптер, майларда...
Шат елмаеп,
Горур җырлап киттең бездән,
Бик аз калгач шаулы язларга.
Көзен килде
Син сагынып көткән язлар,
Нур-шатлыкка күмеп дөньяны.
Октябрьдә
Чәчәк атты синең гөлләр...

Көзге гөлләр була чыдамлы.

*1964*

## АК ВӘ КАРА

Күккә баксаң, ак болытлар
агып бара,
Җиргә баксаң — көз җиткәнме? —
бар җир кара.
Ак вә кара, ак вә кара.
Тәрәзәмдә тулган айның
ак шәүләсе,
Ә шәүләдә — Кушбаш кошның
күләгәсе.
Ак вә кара, ак вә кара.
Кайда соң сез, яклаучылар —
изге җаннар?
Дүрт ягында баш калкыта
хамелеоннар.
Ак вә кара, ак вә кара.
Төн үтәр дә таң атар дип
көтә халык.
Галактика йолдызлары
сибә аклык.
Ак вә кара, ак вә кара.
Йолдызлардан очкын ал да
яктырт Җирне,
Яндыр утта коллык дигән
яман чирне.
Ак вә кара, ак вә кара.
Ак вә кара...

*1992*

## «ДУЛКЫННАР» ЦИКЛЫННАН

### 1. Беренче уй

— Зур Иделгә тиң ул,
шаулары бар, — дисең, —
Күкрәгендә шашып кайный
ак дулкыннар,
әй, күр, — дисең.
Елгасының ярлары тар,
тик күрмисең.
Дулкыннарның
шуңа бәрелеп
тынарын син ник белмисең?
Шаулар анда,
шаулар монда,
шаулар ел да.
Ни файда соң
ул шаулардан.
Без күрмәгәч,
ил күрмәгәч.
Нинди ярсу була ди ул,
нинди елга,
шашуларын, ярсуларын
Диңгезләргә җиткермәгәч?!

### 2. Икенче уй

Исеңдәдер:
Дулкын кебек шаулап,
бөтерелеп
ыргылдың син
комлы ярларга...
Гүя синең белән
алтын балыклар да
Күтәрелде ярны карарга.
Җил котыра,
Дулкын шаулый...
Ә без юкә салда
Дулкыннарга каршы барабыз.
Яннан сугып,
Кинәт ярга бәрмәсен дип,
Дулкыннарны каршы алабыз,
Дулкыннарга каршы барабыз.
Җил басылды,
Шау-шу тынды...
Исән-имин үттек
упкыннардан.
Ә ярларда...
Чүп-чар һәм күбек кенә
Җыелып калды дулкыннардан...

**3. Өченче уй**

Йөзәр диңгезебез шаулы иде,
Җилкендерде шуңа күңелне.
Хыялларны җилкән иткәч кенә,
Ник калдырдың ялгыз үземне?

Икәү корган хыял җилкәннәрен
Читен миңа алып баруы.
Юнәлешен җилләр тиз үзгәртә —
Ялгыз авыр дулкын яруы.

Кайсы яннан бәрә, кайсы алдан,
Кайсы юри сиңа үчләнә...
Диңгеземнең уртасында торам —
Хәзер инде миңа нишләргә?

Ялгыз гына чыга алмам кебек,
Үтә алмам кебек ал ярга.
Миңа, ахры, дулкыннарда калып,
Мәңге дулкыннарда кайнарга!

*1966*

## ӘСИР ТУРГАЙ

Очар канатларын каерып,
Бикләп куйгач зур бер кетәккә,
Сөенделәр Әтәч малайлары,
«Шул кирәк! — дип, — сиңа, тинтәккә!»
Зәңгәр күкләр бетте Тургай өчен —
Һаваларда очу юк инде.
Канатларын чишә күрмәсен дип,
Сакчы Әтәчләр дә куелды.
Ничә еллар аны кол хәлендә
Өйрәттеләр бары эшләргә —

Тиреслектә көн-төн ризык эзләп,
Әтәч өчен җирдә яшәргә.
...Шуннан бирле шактый сулар акты,
Әтәч була язды «тинтәк» тә...
Әмма ләкин шулай дисәк тә,
Тургайлык ул сүнми йөрәктә.
Гауга купкач янә кетәктә,
Юрадылар кошлар бәхеткә —
Әтәч малайлары алышынды,
«Вак әтәчләр» килде тәхеткә.
Кайбер гадәтләрен онытса да,
Тургай яши, әле үлмәде.
Ниндидер бер үҗәтлеге килеп,
Очып карарга да теләде.
Җилкенде дә күккә күтәрелде —
Ә әтәчләр өнсез калдылар.
Тик бераздан, һушларына килеп,
Бар дөньяга сөрән салдылар:
«Ки-кри-күк, һай, бичара,
Кылыйк икән нинди чара?
Һай, бу Тургай аламасы,
Очмый торсаң ярамасмы?
Сиңа карап, очар бар да:
Үз иленә очар казлар,
Тәкәрлекләр сызар сазга…
Бөтенлекне бетерәсең,
Һәлакәткә китерәсең...
Канунда юк һич мондый эш,
Очма, әй, тинтәк, кире төш!
Ә Тургай бүген күктә — иректә,
Әтәчне бирми ул элеп тә.
Кетәк таралыр — бармас күпкә:
Әсир кошлар талпына күккә!

*1995*

*** * ***

Сулкылдап тибә йөрәгең синең —
Хокуксыз иркен төбәгем минем.
Сыкранып яши ник соң бар халык?
Баксаң, үзеңдә күпме бар байлык.
Әйләнеп кара — үткәнең анда:
Гасырлар йөзә кайгы һәм канда.

Күз яшьләренә ышанмый беркем —
Күпме яшәргә бил бөгеп, өркеп?
Үз байлыгыңа үзең бул хуҗа —
Тик шунда гына бетәр бу нужа.
Әйләнеп кара — үткәнең анда:
Гасырлар йөзә кайгы һәм канда.

*** * ***

*Рәшиткә*

Ирек даулап тынган йөрәгеңне
Сәрхуш җаннар хөкем итә калса,
Басар яшьләр безнең эшне яклап,
Йөрәгендә татар каны акса...
Дастаннарга тиң бу исемеңне
Байрак итеп утка кергән чакта,
Берлек кирәк безгә, ныклык кирәк,

Бүленүдән, Ходай, үзең сакла!
*1997*

* * *

Татар башы күргәннәрне
кай телдә дә
Килештереп, җайлап кына
әйтә алмам.
Әмма шуны әйтә алам:
һәр телдә дә —
Татар башын ашый бүген
хәйлә-ялган.
*1995*

## БҮЛЕНМӘС БЕРБӨТЕН

Бүленмәс бербөтен без, дисең,
Барысын үзеңчә сөйлисең.
Табигать ул, дисең, көйләнгән,
Нәкъ бербөтен булып төйнәлгән.
Үрмәкүч тоткан бөҗәкләр дә,
Мәче эләктергән үҗәтләр дә,
Чуртан тоткан вак балыклар да,
Аксак кәҗә йоткан ак гөлләр дә,
Ирекле һәм ирексез көннәр дә —
Барысы бүленмәс бербөтен,
Менә шулай, татар Бөркетем...
.................
Алдыйсың, ышанмый күңел,
Юк, болар һич бербөтен түгел.
Бар нәрсә бүленә Галәмдә,
Керәләр төрле гамәлгә.
Белсәң икән син барсын да:
Бүленә хәтта атом да.
Кирәк чакта, әйе, бүленә,
Тели икән, кабат берегә...
Менә шулай, урыс Бөркетем, —
Юк җирдә бүленмәс бербөтен.
*1995*

## МӨРИТ

*Юныс Әмрәгә ияреп*

Беләм инде — ялганчы син,
Күзгә карап алдаучы син.
Комсызларга кул изисең,
Ә хаклыкка юл бирмисең.

Ильич кебек кайчак үзең —
Зурлау көтә синең күңел.
Мактанырга яратасың,
Булмаганны кабартасың.

Каны саркый Ичкериянең,
Хәерчеләр басты җирне.
Көн туды исә халык бөлә,

Каш астыннан комсыз көлә.

Алып җаннар инде түнде,
Ач яшәргә ишәк күнде.
Туучыдан үлем ишле,
Ил дигәннең сүнә көче.

Йөрәгеңә ямау салып,
Канлы кулга комган алып,
Былчырагын юмакчысың,
Кабат изге булмакчысың.

Сез тудырган зур золымны
Юып кына, әй, булырмы?
Кылган эшең җиде батман,
Инде мин дә йоклап ятмам.
Үсеп җитте зар агачым —
Туган туфрак карагачы.

*1997*

**КАРА ХАТ**

Кайгы килсә,
Читләп үтеп булмый:
Ул тау түгел,
Түгел упкын да.
Эләктереп алса, әй яндыра
Йөрәгеңне мәхшәр утында...
Мәрьям апа әнә
Шашып үкси —
Язар сыман тоела акылдан.
Онытылып елый.
Ә кайгысын
Төшенер ул әле ахырдан.
Күздә яше беткәч,
Айныр да ул,
Хатка багар кабат каңгырып.
Коры буран,
Коры уты белән
Йөрәккәен алыр яндырып...

*1997*

**КИПТЕ НИГӘ КҮЛЛӘРЕМ?**

Яшь чагымда Низамкүлдә
Йөзә иде аккошлар.
Күл өстендә уйный иде
Аҗаганнар, балкышлар...
Нәкъ шул күлдән Баҗанага
Ага иде бер Чишмә.
Шушы Чишмә күлнең серен
Чит елгаларга чишә.
Һәр ел саен үзе һаман
Тирәнәя, киңәя...
Шул Чишмәне хәтерләтеп,
Йөри җирдә киная:
Зур булсаң да, күл булсаң да,
Суым мул дип ярсыма.
Чишмәләр дә житә кайчак

Зур күлләрнең башына.
Күлгә түгел, күлдән аккан
Чишмәләрнең эше бу.
Телгә килми, телдән киткән
Маңкортларның эше бу.

*1997*

**ӘЙ, СИН, КЕШЕ...**

Ник явыз син, ник усал син
Бу кадәрле, әйтче, кеше?!
Бер ерткычның җир йөзендә
Сиңа инде җитмәс көче.

Күгәрчендәй гөрлим дисәм,
Гөр-гөр килеп өй түрендә,
Рогаткалы малай тора —
Мәрхәмәт юк һич күзендә.

Кошлар булып очар идем,
Кемдер әнә ядрә кора.
Балык булып йөзим дисәм,
Су читендә җәтмә тора.

Гөлләр булып үсәр идем
Гөрләп торган бакчаларда,
Гөлләргә дә тынгылык юк
Кеше барда, акча барда.

Колынкайдай чабар идем,
Уйнар идем далаларда,
Аны да бит иткә диеп
Озаталар калаларга.

Бәлки, аю булырмын мин,
Тәртип була аю барда.
Алай дисәм, урманнарда
Бетеп бара аюлар да...

Шуңа да мин кеше булып
Тууымны аклый алам:
Кеше булгач, кешеләрдән
Үз-үземне саклый алам.
Ник явыз соң, ник усал соң
Бу кадәрле, әй, син, кеше?!
Бер ерткычның җир йөзендә
Сиңа инде җитмәс көче.

*1997*

**БАЛ ДА ӘЧЕ...**

*Бер журналистка*

Бер карасаң, сүз чишмәң дә
Күптән инде кибеп бара.
Бертуктамый су коясың —
Ансына да көнеп барам.

Мактан әйдә, күңеленә
Хуш килгәндә, ошаганда.
Суны сөймәс тавыклар да
Суга гашыйк — сусаганда.

Көн туды исә син эфирда,
Ярый да бит буталмасаң.
Бал да әче, күп кулланcаң,
Вакытында тукталмасаң.

*1997*

**КЕНДЕК**

Шушы җирнең төп кендеге итеп
Үзеңне син күпме хис иттең?..
«Миннән башка мәңге Җир әйләнмәс,
Кояш чыкмас», — диеп,
                син киттең.
Җир әйләнә,
Көн дә чыга Кояш,
Сандугачлар сайрый талларда.
Тик бирәрсе
Искә алсын иде:
Кендек, диеп, йөри кайларда?
Юк шул!
Син түгел, арба кендеге
Кирәгерәк бүген чын иргә
«Җир кендеге»
Сына барган саен,
Яшәү җиңел кебек бу Җирдә!

**МАҢКОРТ МОНОЛОГЫ**

Бүре кебек чәйнәп өзәр идем
«Милләт» диеп йөргән кешене.
Ягез әле, уйлап карыйк менә:
Паспорт бирү алар эшеме?

Мөстәкыйльлек җитмимени инде,
Хокук биргәч сиңа уйларга?
Уйдан эшкә күчеп, пүчтәк җаннар
Ут беләнме тели уйнарга?

Бер шовинист җанын тәслим кылса,
Гаеплене эзлим җан атып.
Ирек даулап тынган чечен күрсәм,
Шулай кирәк, димен, «яратып».

Хокукнымы, беләм, чикләү кирәк,
Эшләү кирәк җайлап, астыртын.
Тоттыр аңа «молоткастый» түгел,
Кушбаш төшкән импер паспортын.

Милләт, телен язма, исемен боз —
Онытсын ул каян килгәнен...
Йөрсен: «Империя гражданы мин —
Укыгыз,
     белегез,
          көнләгез!»

*1997*

## ЯҢА КОММУНАРЛАР

Еллар буе акча алмыйм, дисең,
Коммунарга нигә кирәк ул?
Бомжларны күр син: фатирлардан
Урманнарга күчкән өрәк ул.

Барсы, барсы күптән уртак инде,
Юрганнар да уртак, бербөтен.
Ана — улны, ата кызны белми,
Яшибез без гөрләп, бөркетем.

Милләтләрме? Исемнәре белән
Җисемнәре бетте буталып.
Татардан да калып бара илдә
Маңкорт дигән уртак бер халык.

Дәүләтнең дә кирәге юк хәзер:
Суды-ние череп таркала.
Килде илгә халык көтеп алган
«Коммунизм» дигән тантана.
(Ленин алдан күргән, йа Алла!)

*1997*

## ЙОМШАК ҖӘЕП, КАТЫГА...

Йомшак кына исә җилләр бүген,
Йомшак басып кердек базарга.
Муллык үзе килде безгә бүген,
Бар нәрсә бар — җаның ни тели.
Мул ризыкка карап туя тамак,
Җитмәүчелек, димәк, көтелми.
Еллар буе акча алмый халык,
Алса да ул ала ипилек.
Һәр чат саен дога кыла картлар,
Түрәләргә теләп иминлек.

*1997*

## Ю ГӨНАҺЫҢ!

Күпме гасыр гадиләргә
Сан булмады бу илдә.
Изелгәннәр гел изелә —
Шаһит моңа Идел дә.
Тарих белми бәндәләрнең
Тук булганын бу илдә.
Эшләсә дә, кол булганга,
Ачыга ул бүген дә.
Тарих белми бәндәләргә
Көн булганын бу илдә.
Талый, сата Чубайслар
Илнең инде үзен дә.
Ни сәбәп соң, нигә болай —
Тәңреме соң каргаган?
Бабамнарның күз яшедер —
Шулардан ул каргалган.

Казан башка чыкмый торып,
Бәхет килмәс бу илгә.
Афәт кенә килә торыр —
Гөнаһың ю Иделдә!

*1998*

## САК БУЛ, ДИ АК КЫШЛАР...

Сузылды ул куллар җилләрдә уйнаган
ак карга...
Яшь булып эреде кулында — әйләнде
ак парга.
Кызыгып чәчәген өзде ул алманың —
ай Алла!
Көз җиткәч, бакчада ким иде, җитмәде
бер алма...
Маймычка кызыгып, тотты да ташлады
комлыкка.
Мескенем буылып-буылып талпынды
сулыкка...
Ә бүген сиңа бит, сиңа бит үрелә
шул куллар.
Сак бул, ди бакчалар, ак карлар,
дулкыннар...

*1998*

## БАКА КҮЛЕ

Төннәр буе бакылдый ул
бака күлендә.
Йокым кача, нәфрәт баса,
ачу — күземдә.
Әй туйдым соң бу бакадан,
авыр күңелгә.
Төннәрен, әй, рәхәттер ул
бакасыз күлдә.
...Кабул булдымы теләгем —
сазлык-күл кипте:
Бакалар да, мине ташлап,
каядыр китте.
Күлләр кипкәч, әй талпынып,
гүзәл бер таңда,
Сайрады былбыл, сипте моң
минем бакчамда.
Бакаларым сагындырып куйса да
кайчак,
Былбылың булсын бакчаңда,
булсын ул һәрчак.
Назлап кына йоклата ул
мине һәр кичтә.
Сайрап кына уята ул мине
һәр иртә.
Уйлап баксаң, бака тыңлап
ничә ел үткән.
Бака туеннан күңелем, белмим,
ни көткән?
Ни өмет иткән?

*1999*

## КУЯН ЕЛЫНДА

Бигрәк юаш, дип, куянны
Кыерсытма, елатма.
Кыерсытсаң һаман болай,
Әйләнер йә елакка.

Көт яхшылык яхшылыктан,
Яманлыктан көтмә син.
Өркетми тор куянны да,
Йә арыслан итәрсең.

*1999*

## * * *

Югары менгән чакларда да
Аска карап, безгә багу,
Илгә багу бик кирәк.
Төшәр юл ул кыя-ташлы.
Имгәнмичә йә үлмичә
Төшүчеләр бик сирәк.

*1999*

## ЙӨРӘГЕҢДӘ — ХАЛКЫҢ МОҢЫ

*Саре Нурига*

Кырымнардан куылдың син,
Мариларда туендың син.
Казаннарда кайнар өчен,
Кәбирләргә* сыендың син.

Баскыннарга нәфрәт тулы
Күзләреңдә һәрчак — Кырым.
Кырымчаннар — москаль колы,
Сыный дөнья Кырым кызын.

Кырымда туып, Казаннарда
Балкыдың син, Саре Нури.
Йөрәгеңдә — халкың моңы,
Күзләреңдә өмет нуры.

*1999*

## РӘСӘЕМ МИНЕМ

Нинди бай ул минем Рәсәй илем:
Нефтьләре, алтын, ураны...
Халкын талап уңышка ирешкән
Илнең җирдә бармы булганы?

Нинди горур минем Рәсәй илем,
«Ирек» дисәң, җаның киселә.
Үзенең халкын канга батырган ил
Бармы җирдә — төшер исеңә!

Нинди гадел минем Рәсәй илем,
Тоеп яши моны халык та.

Парламентын утка торткан илләр
Булды микән, сора халыктан.
Булыр микән тагын тарихта?!

*1999*

**ВАКЛАНМА**

Бик кечкенә эшләреңне күреп,
Туган халкың шуңа сөенсә,
Көнче затлар, «озын» һәм «биекләр»,
Бушкуыклар гына көенсә,
Су буедай мактау сүзләренә
Исемеңне алар кертмәсә,
Зур эш кылган сыман, аннары
Сукыр тавык кебек кертләсә, —
Татарыңны синең бүлгәләүче
Шушы затлар булыр, туганым.
Тик гасырлар шаһит, алар белә
Туган халкың шулар буганын.
Кечкенә бер уңышыңны күреп,
Гади халкың рәхмәт белдерсә,
Иңнәреңә кулын тидерсә,
Җиденче кат күккә күтәрел:
Бушкуыклар шундый үртәлер...

*1999*

**ТАУ БӨРКЕТЕ**

Тамырларда, геннарында мутант,
Шуңа гарип, шуңа гораба.
Ике башлы булып туса да ул,
«Мин бөтен» дип һаман сөйләнә.

Тау бөркетен талый бу кош бүген,
Гариплектә аны гаепләп.
Төшеп калганнардан түгел бөркет —
Ике башын чукый бик иплэп.

Гарип-горабага кол булуны
Хурлык саный бөркет баласы:
«Йә азатлык, хөрлек аласы,
Яки тауда ятып каласың...»

«Текә кыя, тауларыңда, балам,
Бары бөркетләрчә яшә син!»
Һәр бөркетнең изге хыялы бу,
Башкача ул ничек яшәсен?!

Дөресе шул, чыны, чып-чыны,
Идел тавыгы да түгел алар,
Түгел алар Урал чыпчыгы.

*1999*

**МӘҢГЕ ЯШЬ КАЛДЫ**

Унсигезе дә тулалмый калды,
Чәчәк-бөреләр ачылмый янды.
Иң чибәр кызлар сөелми калды,

Тәүге туйларда биелми калды.
Әти кеше дә булалмый калды,
Нәниләре дә туалмый калды.
Чәчәк-бөреләр ачылмый калды,
Унсигезе дә тулалмый янды.

*2000*

*** * ***

Өстәлемдә тора кабырчыклар.
Диңгез шавын тоям аларда...
Югославия. Белград.
Кавказ. Чечен иле —
Хәтеремдә барысы яңара.
Мин беләмен
Бүленмәскә килгән
Бер әйбер дә югын бу Җирдә.
«Чечен илен кулдан ычкындырмыйм,
Җибәрмимен» диеп тилермә!
Ил гомерен озайтамын дисәң,
Колак сал син халык сүзенә.
Карышасың икән,
Дуслык чылбырының
Буыннары шундук өзелә.
...Кабырчыклар шавы:
«Чылбырың өзелә, өзелә, өзелә...»
Шулай була калса,
Ничек карарсың син
Киләчәк буыннарның күзенә?!

*2002*

## ТИМЕР БУЛУ ГЫНА ҖИТМИ

*Якташыма*

Халкыбызга ныклы калкан булып
Калыктың син илдә, Минтимер.
Атаң-анаң кушкан исемеңә
Тугры калдың, әйе, син — тимер.

Өлкән агай кабат баш калкыта —
Хуҗа булу хисе китмидер.
Империя аңга килсен өчен,
Тимер генә булу җитмидер.

Ил өстенә үрли ут ташкыны,
Кабат басты алга зур бурыч:
Бөгелмәстәй, утта эремәстәй
Булсаң иде бүген син корыч.

*2000*

## ТАЗА ШАҺГАЛИ

Бакчасында түрә булалмагач,
Чит бакчага барып ялланды.
Шул бакчага аның җаны фида —
Бер алмага, мәхлук, алданды.

Төп бакчада үскән гөлләре дә

Чәнечкедәй аңа барсы да.
Үз бакчасын бакча түгел, диеп,
Кенәри кош бүген ярсына.

Имеш, анда алма алмамыни,
Чияләр дә бик вак күренә.
Җиләкләре инде күптән кипкән,
Карлыганнар кара түгелләр.

Имеш, анда тимер хаким итә,
Тимере күп җиләк-җимештә.
Алмаларын ашыйм дисәң әгәр,
Ашап булмый — авыз бөрешә.

Мондый бакча нигә соң Рәсәйгә,
Нигә безгә андый «тимерләр»?
Кешеләр дә кеше кебек түгел,
Язучы юк, барысы тилергән.

Әгәр миңа рөхсәт итсәгез сез,
Ул бакчаны кайтып җимерәм.
Кенәри кош, үз бакчасын сатып,
Шулай оя кора чит җирдә.
Кайчан, белмим, кайчан гына икән
Шаһгалиләр бетәр бу җирдә?!

*2000*

**ДУМА ДЕПУТАТЫ**

Сайлаганда тау-тау вәгъдәләр биреп,
Сайлангач, шул тауларда югалды эреп.
Мәгънәсе бер: моннан соң кабарбыз өреп.

*2002*

**ДӨНЬЯ БЕТМИ...**

Ахырзаман...
Дөнья бетә, диләр...
Ничек инде бетсен ди дөнья?
Дөнья бетми, бары намус бетә,
Әхлак бетә, бетә һәм вөҗдан.
Кысалары инде күптән тузган,
Кеше бетә, бетә кешелек...
Җиттем менә шуңа төшенеп.

*2001*

**БЕТСЕН ТЕРРОР**

*(Ярым шаяру)*

Көн тәртибендә, әфәнделәр,
Карала бик мөһим мәсьәлә:
Олуг Америка кунагы
Интегә. Сәбәбе нәрсәдә?

Колорадо «дус»ка, чынлап та,
Җитешми иң тәмле бәрәңге.
Киңәйтик чәчүлек мәйданын,

Үссен ул җитәрлек кадәрле.

Җитсен ул коңгызга, безгә дә,
Саран булырга һич ярамый.
Чәчүлек орлыгын хәзерлик
Бернинди моң-зарга карамый.

Әгәр дә дус яшик дисәгез,
Колорадога сез тимәгез.
Үзегез беләсез сәбәбен —
Буш яратмый террорлык гамәлен.

*2002*

## ИСЕМЕ ХАКТЫР

Кызыл мәйдан... Чыгышы кайдан:
Ярлыданмы әллә байдан?
Кызыл булмый нинди булсын —
Ул бит безнең изге мәйдан!

Изге дисәң, ник соң әле
Тәресе бар, мәхрүм Айдан?
Дүрт йөз илле ел эчендә
Күпме җаннар монда янган.

Бабайларның изге каны
Ник соң әле монда тамган?
Кызыл мәйдан — канлы мәйдан,
Исемне ул дөрес алган.
Күпме генә акшарламыйк,
Акшар куба — чыга ялган...

*2002*

## ЛОГИКА

Мин политик түгел, шагыйрь генә,
Мин көрәшче түгел, җырчы мин...

Фиркаләргә, дөрес, кермәдең син,
Сыйнфый аңым, дидең, чиклерәк.
Шулай булгач, «йөрәгеңә терәп
Атулары» менә шиклерәк...

Аерым яшәп булмый кешеләрдән,
Качып булмый уртак кайгыдан.
Шагыйрь булгач, димәк, көрәшче дә
Буласыңдыр инде, шагыйрь җан.

*1997*

## МАНЕЖДА

Манеж кайный... Демократлар
Барлый бүген үз көчен.
Һәммәсенең телендә бер:
«Бүленмәс Рәсәй өчен!»
Хурлык сиңа, Горячева —

Горбачев шестеркасы!
Кит властьтан, партократ —
Шул булыр иң яхшысы!
Кэпээсэс, чиген, давай,
Бетте синең көннәрең.
Рәсәйдә исә бүген
Бөек Ельцин җилләре.
Рәсәйне бүлгәләү ул —
Бары тик уйдырмалар.
Бетсен мәңге автономнар,
Яшәсен губерналар!»
Болар өчен Ил кирәкми,
Тик Рәсәй бөтен калсын.
Болар өчен бары тик кол
Рәсәйдә татар халкы.
Башкаларның иреген буган
Ил ирекле буламы?
Болар җиңсә, Рәсәй булыр
Демократлар ГУЛАГы.
Манеж кайный. Барысы шаша,
Барысы барлый үз көчен.
Демократлар телендә бер:
«Бүленмәс Рәсәй өчен!»

*1991*

## ШОВИНИСТ МОНОЛОГЫ

«Московские новости» бинасы янындагы
көфер почмагында сөйләгән чыгышы

Христосны күрә алмыйм —
«Дошманың ярат, — дигән, —
Түзем бул, адәм, түзем бул,
Болытны тарат», — дигән.
Коръәндә бит андый сүз юк,
«Дошманың — кяфер» дигән.
Шуңа да мин кайбер вакыт
Коръәнгә башым иям.
Ник мөселман әйбәт яши,
Ник соң әле без фәкыйрь?
Чөнки барлык дошманнарын
Яратып яши кяфер.
Ельцинны да күрә алмыйм:
Барын әзер сатарга.
Эшенә керешмәс борын
Ирек бирә татарга.
Библиядән алмый торып
«Дошманың ярат» сүзен,
Ельцин түгел, җен килсә дә,
Ипигә туймас күзем,
Ирекле булмас Илем.

*1991*

## КЫЯТАШЛАР БУЛЫП...

Вәхшилектән ничек туйганымны
Белсәң иде әгәр син, белсәң...
Кыяташлар булып калкыр идем,
Менәреңне әгәр мин белсәм.

Туйдым, дускай, туйдым вәхшилектән,
Җаным туйды талау, алдаудан.
Телен, денен сатып алданганнар
Котыла алмый бүген ялганнан.

Учларымда учак ягар идем,
Кызганмыйча әгәр син түзсәң.
Мәңгелеккә китеп барыр идем,
Килереңне әгәр мин белсәм.

Тере килеш йотар кебек бары,
Сыгыла калсаң әгәр, бил бөксәң.
Кыя ташы булып калкыр идем,
Менәреңне әгәр мин белсәм,
Менәреңне әгәр мин белсәм...

*1998*

**Кабынды бер йолдыз**

*** * ***

Шагыйрь түгел үзе, әмма гашыйк,
Гыйшкы булгач, шагыйрь инде ул.
Һәрнәрсәдә яңа төсләр таба,
Бар нәрсәдә күрә шигырь ул.
Тормыш дигән гөлбакчадан аңа
Чәчәк-чәчәк сөю тулачак.
Миллион еллар инде шулай булган,
Бездән соң да шулай булачак.

**КИЧЕР!**

Кичер син, кайтмаска киттем мин,
Кайтмамын бирегә сагынып.
Яфраклар коела бакчада,
Сагыштай, коймага сарылып.
И, кичер, кайтмаска киттем мин,
Кайтмамын юксынып, зарыгып.

Кичер син, моннан соң көтмә дә,
Сөялеп яшьләнгән тәрәзгә.
Кайталмыйм мин сиңа, кайталмыйм,
Утларың янса да тәрәздә.
Вакыт ул — барсына чын дәва,
Күнәрсең бу гадел хәбәргә.

Усал син, тик миңа мөлаем,
Ә үзем мин усал синнән дә.
Су кирәк, су кирәк гөлләргә,
Беребез теләми сибәргә.
Ничек соң теләсен яшьлегем
Гөлләр күк тилмереп кибәргә?!
Мин булган бу шаулы кичәдән
Парлылар беттеләр таралып.
Яфраклар коела урамда,
Сагыштай, юлларга сарылып.
Кайталмыйм мин сиңа, кайталмыйм,

Көтсәң дә, кадерлем, зарыгып.

И, кичер, мин сиңа кайталмыйм,
Әйләнеп кайту юк үткәнгә.
Оныт син барын да бу көздә,
Көзләр бит сагыш ул — көткәнгә.

## СЫРГАНАКЛАР СЫМАН

Язлар килгән саен, бакчабызда
Ак күлмәген кия алмагач.
Ник керден соң шау бакчама минем,
Аклыкларын аңлый алмагач?

Җәйләр җиткән саен, шул бакчада
Кызарып пешә кура җиләге.
Миңа түгел, җиләкләргә дә син
«Җиләккәем минем» димәдең.

Алмагачтан алма алмагачтын,
Ник килдең соң бире зарыгып?
Кайлардадыр калган яшьлегеңне
Үтте, ахры, гомереӊ сагынып.

Сары сагыш сыман бакчабызда
Сырганаклар пешкән сарылып.
Көзләр инде җиткән, учагыбыз
Китә алмас, ахры, кабынып...

## КҮЗКӘЙЛӘРЕҢ СИНЕҢ — ТИРӘН ДИҢГЕЗ...

Күзкәйләрең синең — тирән диңгез,
Керфекләрең — таллы ярлары.
Дулкынланып алса әгәр диңгез,
Чыланмыйча калмый таллары.

Күзкәйләрең синең — төпсез диңгез,
Никадәрле сагыш, моң сыйган.
Ярларыннан күрәм: бу диңгездә
Аз булмаган шашып ярсулар...

Давылдан соң кайчак тынып калса,
Беткән димә сагыш, сөюләр:
Иркәләнер һәм назланыр өчен,
Үз җилләрен көтә диңгезләр...

*** * ***

Баш очында соры болыт
Сибәли дә сибәли.
Аңа карап, эше пешмәс,
Көзе җиткән, димә әле.

Күз ташла син түр бакчама:
Шау чәчәктә гөлләрем.
Көткән язлар гөлләремә
Соңлап килде көзләрен.

Сорама син, юк, сорама,
Ник соңарды язың, дип,
Көзен килгән язларымның
Көне аның елга тиң.

*1961*

## ТУЙДАН СОҢ...

*(Егет монологы)*

Ничек кенә саклandың да, ничек түздең?
Дәрт туганда нәфесеңне ничек бүлдең?
Тәннәреңдә кер кунмаган олуг сафлык,
Тыгыз, тулы күкрәкләрең тора калкып.
Минем куллар кагылгач тик, киттең йомшап.
Калдың менә изге җанга үзең охшап.
Саклангансың, кагылмаган ятлар кулы,
Сибелә тугры күзләреңнән бәхет нуры.
Тормышымны сафлык белән син бизәдең,
Рәхмәт яусын, гүзәлләрнең, әй, гүзәле.
Мин үзем тик Эзоп түгел, Эрот кына,
Тик шулай да яшәрбез, дим, җырлап кына,
Дөньябызны матурлыкка буяп кына.

## КИТТЕҢ СИН...

Киттең син...
Син киттең өнемнән,
Тын гына, моң гына
Киттең син төшемнән...
Ә үзең...
Яшәп тә янәшә,
Юату, сүз кату
Килмәде көчеңнән.
Беләмен,
Син миңа ул таңда
Сөелеп, сөенеп,
Сагынып килмәдең...
Кайдадыр
Бер янган яшьлекнең
Эзләрен син миндә,
Ник миндә эзләдең?
Үч алу мишене иттереп
Ник мине, моңлы күз,
Ник мине сайладың?
Бер генә
Бирелгән гомерне
Ник болай,
Әйт шуны,
Ник болай алдадың?..

## * * *

Тылсымлы сүзләрең белән
Исерт кабат бүгеннән.
Серле күзләрең белән тик
Сихерлә син, үтенәм.

Сихерләнеп бу язларда
Яшәрмәсме яшьлегем.
Язлар гына җылыта, диләр,
Уртак яшьлек бишеген.

Алдала син: килсен язлар,
Барсына түзә алам.
Чәчәкле чагың үтсә дә,
Никтер мин һаман янам...

Шунсы кызык: мин үземне
Бик җиңел алдый алам.
Алданам да, баешыма
Елмаеп китеп барам.

Беркайчан да мин боларга
Үкенмәмен, үкенмәм.
Серле күзләрең белән тик
Сихерлә бер, үтенәм.

**КАЛАМДА КӨЗ**

Тиктормас җил инде тынып калган,
Җылыналар кошлар җыелып.
Җылы тапмый ертык болытлардан,
Томан ята җиргә сыенып.

Чаган яфракларын җыя-җыя,
Көзгә керәм, кышка ашыкмыйм...
Казан көзләренә гашыйкмын мин,
Кызларына мәңге гашыйкмын.

*1989*

*** * ***

Көзнең сары җырларын
Җилләр чәчә дөньяга.
Бер карасаң, яфраклар,
Бер карасаң, кар ява...

Ә наратлар тын гына
Җәйне саклый урманда.
Сары җилләр дә тими,
Суык та тими аңа...

**КАЛЫР ИДЕМ**

Гудаута.
Соңгы тапкыр сакта торам.
Ишетәм мин
Соңгы тапкыр кипарислар шаулавын.
Пальмаларның
Соңгы тапкыр кыштырдавын.
Күзәтәм мин
Соңгы тапкыр Төркиянең ярларын.
Мең дә бер йөзенче тапкыр

Ил чигендә:
Барсы якын,
Барсы таныш,
Барсы күркәм күңелгә.
Дулкыннар да
Сөйләшәләр үзләренчә.
Мин төшенәм...
Мин дә сөйли беләм
Алар телендә.
— Ташлап китмә,
Безне моңсу итмә, — диләр гүя, —
Кавказ тауларыннан,
Диңгез ярларыннан туймасаң...
Их, дулкыннар!
Калыр идем сезнең янда,
Казан дигән җирләр,
Идел дигән сулар булмаса...

*1959*

**ЯШЬ ШАГЫЙРЬЛӘР**

Үзләренә егермедер, булса, —
Янып торган япь-яшь шагыйрьләр.
Кара-каршы басып, бер-берсенә
Укый алар яңа шигырьләр.

Янып сөю, яшьлек турындадыр
Язылганның шактый өлеше.
Елмаялар...
Тик белмиләр алар
Өлешенә тияр көмешне...

Язган шигырьләрдән кемнәр укыр,
Ни өстәрләр шигъри байлыкка?
Яфрак-яфрак кына китап язып,
Танылырлар кайчан халыкка?

Кемдер калыр,
Кемдер янар, сынар,
Кемдер җитәр изге максатка...
Еллар сыгар,
Ялгызлыкта алар
Берәм-берәм китәр бер якка...

Тик аңарга әле ярты гасыр,
Ул турыда кем соң уйласын?
Яшь шагыйрьләр яңа шигырь укый —
Зәңгәр күктә апрель кояшы.

*1964*

**ДИАЛЕКТИКА**

Плюслар нигә?
Нигә минуслар?
Уңышсыз эшләр
һәм дә уңышлар?
Нигә яшәү,
нигә үлем кирәк?
Шулай...

каршылыксыз нәрсә сирәк.
Җирдә шулай ук
шатлык бар,
сагыш бар...
Алар да каршылыклар.
Шатлык килсә,
сөенәбез.
Кайгы килсә,
көенәбез.
Сагышлар бетсен, дибез,
Шатлык кына телибез.
Тик уйламыйбыз
кайгының шатлыксыз булмавын,
шатлыкның сагышсыз тумавын.
Әгәр дә кайгылар булмаса,
Сагыштан күңелләр тулмаса,
Тоймас идек шатлыкның
үзен дә,
ямен дә,
тәмен дә.

### КАБЫНДЫ БЕР ЙОЛДЫЗ...

Җил гүяки канатланган бүген,
Күрше кызын үрти шаяртып:
Битләреннән үбә, кочмак була,
Чәчләреннән сыйпый яратып.

Ә сөйгәне кызның, тәрәз ачып,
Бармак яный җилгә, көнләшеп:
«Арабызга ятлар түгел, җил дә
Кермәс, диеп куйдык сөйләшеп».

### УЯТТЫҢ

Котмәгәндә иңгән нур шикелле,
Гамьсез күңелемне уяттың.
Талпындырып тыныч йөрәгемне,
Башкаема бетмәс уй аттың...

Уй аттың да мине уяттың,
Уяттың да бетмәс ут аттың.
Сөюләрең хәләл булмагач,
Ниләремә генә уяттың?!

*1999*

### КАРЛЫГАНДАЙ КҮЗЛӘРЕҢ

Бакчаларда карлыганым
Өлгергән бит — җый гына.
Икәүләшеп карлыганны
Җыябыз без җай гына —
Җыюлары ял гына.

Иң өлгергән чагында, дим,
Өзеп кенә кабыйм ла.

Алган идем авызга —
Карлыганым бал гына ла,
Карлыганым бал гына.

Карлыган гел бал булса да,
Күзем синнән алмыйм да.
Карлыгандай күзләреңне
Бутамасам ярый ла,
Бутамасам ярый ла.

*2000*

*** * ***

Нигә, нигә генә әле
Яшь ананың фикере чуалган?
Сабыена теккән ак күлмәк
Кайнар яше белән чыланган...
Нигә әле, нигә чыланган?..

*1999*

## КӨЗГЕ ТЫНЛЫК

Коелганда усак яфраклары,
Көзге көннән сары ут алып,
Бакчаларга кереп адашкан җил
Тынды яфракларга буталып.

## ТУННЕЛЬ

Кинәт...
Кояш сүнгән кебек булды,
Килеп кергәч тирән туннельгә.
Белмим,
Үзенә күрә рәхәт тә,
Ямансу да кебек күңелгә.
Шулчак
Капыл баскан караңгылык
Куркыттымы сине — сизмәдем.
Күрәм,
Караңгыда синең куллар
Минем кулларымны эзләде.
Истә...
Туннель чыкканчыга кадәр
Кулларыңны кулдан алмадың.
Ни бу?
Курку булдымы соң,
Әллә яратумы?
Тик ахырдан гына аңладым...
Үттек...
Туннель ерагая барды,
Якынайтып безнең араны.
Куллар тоташтырды күңелләрне,
Яңартса да иске яраны.
Шуннан,
Мәңге аерылмас булып,
Беректеләр кебек күңелләр.
Беләм хәзер:
Юлларыңда шулай ара-тирә

Очрап торсын икән туннельләр.
*1960*

## ЮЛГА ЧЫККАНДА

— Үстеләр канатлар,
Әнкәем, мин китәм...
— Кайларга китсәң дә,
Кайт, улым, мин көтәм!..

Мин киттем.
Әнием озата чыкканда,
Каеннар уянды шыбырдап.
Оясын калдырган кош кебек,
Тәннәрем ник куйды чымырдап?
Әнием күңеле шикелле,
Каеннар шыбырдый җай гына:
«Китмә син, әй, улым, кал инде,
Кал инде бер көнгә, аз гына...»
Еракка-еракка юл буе
Озата бардылар арышлар.
Тоямын: башаклар шавында
Шундый ук бер моң бар, сагыш бар.
Әнием күңеле шикелле,
Башаклар пышылдый тын гына:
«Китмә син, кал инде, әй, улым,
Кал инде бер көнгә, аз гына...»
Башаклар пышылдый тын гына...

*** * ***

Еракта, еракта
кабынды бер йолдыз.
Тартыла күңелем шуңарга,
белмисез.
Бәлки, ул минем йолдыздыр,
ә бәлки, түгелдер.
Кем белә:
әлегә билгесез.
Тартыла күңелем...
җылысын тоймыймын.
Еракта алар соң
ник сүрән яналар?
Күңелне тартырлык
гаҗәеп балкышны,
Нурларны
йолдызлар каян соң алалар?
Минем күк...
Төн ярып,
утларга талпына күбәләк.
Карасаң,
янганы, көйгәне азмы соң?
Ашкынам...
Ярый ла, көтмәсә мине дә
Утларга талпынган күбәләк
язмышы...

## ЯҢГЫРДАН СОҢ

— Ник, сиренем, таҗларыңнан яшьләр тама,
Шатлыктанмы, кайгыданмы бу энҗеләр?
Шул чагында яшьле сирень аваз сала:
— Олы хата эшләдем шул, их, мин, җүләр!
Айлар буе сусыз торгач, мин, түзмичә,
Бу дөньяны тиргәдем бит, оят шуңа.
Җылы яңгыр явып үткәч, шул ук дөнья
Нинди күркәм, нинди гүзәл хәзер миңа...
Шул дөньяны тиргә инде!.. Елыйм шуңа.

## ӘРЕШЕМДӘ МИНЕМ ЯЗМЫШЛАРЫМ

Әрешемдә дәвер язмышлары —
Акрынайган никтер агышлары;
Куерганмы әллә камышлары,
Челтерәми аккан тавышлары?

Моңсу аның никтер агышлары,
Ишетелә гомер сагышлары.
Җиткән мәллә инде баешлары?
Әрешемдә авыл язмышлары —
Әрешемдә минем язмышларым.

*1997*

## МАЙЛЫ ЧИШМӘДӘ

Чишмәләр, дисең, майланды...
Ышанамын — хак сүзең.
Сабый чак чишмәләремне
Кайтып күрдем мин үзем.

Чишмәбезнең, һич шаяртмыйм,
Нәкъ көмеш иде суы.
Шул чишмәгә илтә иде
Бәбкә үләнле юлы.

Чишмәбезгә карап ул чак
Күз кыссам көмеш суга,
Нәкъ үземдәй бер шук малай
Күз кыса иде миңа.

Баксам хәзер шул Чишмәгә —
Май каплаган суларын.
Кемдер карый май астыннан —
Танып булмый кем барын.

Сабый чактагы шук малай
Инде каядыр киткән.
Майлы суда чак таныдым:
Алтмыш яшьлек карт икән —
Ул минем шәүләм икән...

*1997*

* * *

Чыгар диңгезебез шаулы иде,
Җилкендерде шуңа күңелне.
Хыялларны җилкән иткәч кенә,
Ник калдырдың ялгыз үземне?

Икәү корган хыял җилкәннәрен
Читен миңа алып баруы.
Юнәлешен җилләр тиз үзгәртә —
Ялгыз авыр дулкын яруы.

Кайсы яннан бәрә, кайсы алдан,
Кайсы юри сиңа үчләнә...
Диңгеземнең уртасында калдым —
Хәзер инде миңа нишләргә?

Ялгыз гына чыга алмам кебек,
Чыга алмам, ахры, ал ярга.
Икәү бергә булсак, җилкәнебез
Илтер иде әллә кайларга...

## ҖАНЫҢ БАРМЫ, ДИП СОРЫЙСЫҢ...

Җаның бармы, дип сорыйсың,
Чумсам кайчак үз дөньяма.
Андый чакта минем хакта
Әллә ниләр син уйлама.
Бар ул, бар ул минем җаным,
Яна да ул, көя дә ул.
Елый белә, көлә белә,
Онытылып сөя дә ул.
Бер караудa, чишмә кебек
Челтер-челтер ага уйнап.
Ак күңелле кешеләргә —
Сулары ак, сулары саф.
Бер карауда, вулкан кебек
Ялкын бөрки тирә-юньгә.
Андый чакта йөр еракта,
Миңа якын килә күрмә.
Кайчак кимсенүдән ярсып,
Төннәр буе сулкылдый ул.
Шундый чакта бул янымда.
Сөю — дәва! Янымда бул!

## ИКЕ ЗӘҢГӘР УК

Төбәлде миңа
Ике зәңгәр ук.
Ә андый күзләр
Беркайда да юк.

Ике зәңгәр ук
Ник мине күзли?
Кая барсам да,
Йөрәкне эзли.

Йөрәкне таба,
Нишләмәк кирәк:

«Кадал, кадал!» — ди,
Бирелде йөрәк.

## ӨЗЕЛЕП СӨЙДЕМ СИНЕ ЯШЬЛЕГЕМДӘ

*( Җыр )*

Өзелеп сөйдем сине яшьлегемдә,
Аңлатырга сүзләр тапмадым.
Изге хисләремне ни гомерләр
Бары сиңа гына сакладым.

Йолдызлардан көнли идем сине,
Шикләндерә иде ялгыз Ай.
Эчтән янып, тыштан сүзсез йөрдем,
Читенсендем синнән ник болай?

Иреннәрем кипкән, сүзем чыкмый,
Җаным белән сиңа талпынам.
«Әгәр җирдә сөю булса, — дидең, —
Хәзер йолдыз булып атылам».

Син теләгән сүзне әйталмыйча,
Кулларыңа синең кагылдым.
Сиңа дигән сүзләр каян килсен
Телләренә ул чак «сабый»ның?

Ә ул көннәр калды әллә кайда,
Көл булдылар күптән учаклар.
Ник үзәкне өзә-өзә һаман
Искә төшә икән ул чаклар?

Учакларның көлен җил тузгыта,
Җилдәй кыю хәзер үзем дә.
Сүзләре дә житә, нидер җитми
Яшьлегендә янган күңелгә...

## НИНДИ СУСАГАН ИДЕМ...

Белсәң әгәр, синең назга
Нинди сусаган идем.
Киләм, дигәч, куанычтан
Чынлап ышанган идем.
Түр бакчамда сине көтеп,
Шундый юксынган идем.
Яфрак төшсә дә өзелеп,
Син дип ымсынган идем.
Нәркисләргә сөю кушып,
Такыя тезгән идем.
Килмәдең син, күрмәдең син
Сүнгәнен күзләремнең.

*1992*

## КЕМ СОҢ ЖӘЛЛӘР?..

Күзләреңдә — минем шәүләм,
Шундый иде әүвәл хәлләр...
Үз итмәдең, мин фәкыйрьне

Кем соң сөяр, кемнәр җәлләр?

Дөнья булгач, барсы була:
Сөяк булса, ите куна.
Таптым мин дә үз ишемне —
Шулай язган фани дөнья.

Күзләремдә — синең шәүләң...
Тик бүтән шул минем хәлләр.
Белмим менә: сине хәзер
Кем соң сөяр, кемнәр җәлләр?

*1997*

## КҮРШЕ КЫЗЫ

Күрше кызы — уңган кыз ул,
Булган кыз ул Миләүшә.
Бик юксынган чакларында,
Җилләр белән сөйләшә.
Сагынулары басылмаса,
Кошлар белән киңәшә.

Их, Миләүшә, Миләүшә,
Кошлардан да көнләшәм.
Гөнаһ булыр, син сылуны
Әгәр үзем сөймәсәм,
Әгәр үзем сөймәсәм.

*1998*

## МИНЗӘЛӘ КҮПЕРЛӘРЕ

Син дә бит егермедә,
Мин дә бит егермедә.
Егермедә чакларның без
Кадерен белик бергә.

Минзәләнең күперләре
Челтәр дә челтәр генә.
Синең кебек чибәр генә
Китсәм дә көтә белә.

Зәңгәр күзләрең ник әле
Челтәрле күперләрдә?
Сине ташлап, шул күпердән
Дускаең китә мәллә?

Күңелкәем сизгән икән —
Аерды бит күперләр.
Шул көннән соң күпер аша
Еллар сызылып үттеләр.

Син дә инде кырыкта,
Мин дә инде кырыкта.
Яшьлегебез кабат кайтты —
Рәхмәт яусын кырыкка.

Син дә шул ук күпердә,
Мин дә шул ук күпердә.
Егермедә чакларым... дип,
Юк, дускаем, үкенмә.

Син дә бик камилләшкән бит,
Мин дә бик камилләшкән.
Камиллеккә ирештек без
Нәкъ менә илле яшьтә.

*1987*

## СОҢГЫ ТЕЛӘГЕҢӘ СОҢГЫ ҖАВАП

— Яна йөрәккәем,
Соңгы теләккәем:
Исән булсак фани дөньяда,
Бик бәхеткә чумсаң,
Йә бәхетсез булсаң,
Хәбәреңне җиткер миңа да.

— Бәхетле дә димим,
Бәхетсез дә түгел,
Ә шулай да хәбәр юллыймын.
Соңгы сүзләреңне,
Йөргән эзләреңне
Юксынамын, сине уйлыймын.

Сәбәбен беләсең,
Үзәгем өзмә син,
Болай да мин никтер бирештем.
Үткәнгә юллар юк,
Кысарга куллар юк,
Күңелдә булса да күрешик.

Их, минем күз нурым,
Иң соңгы бу җырым
Яшьлектән хат булып ирешсен.
Бәхетсез булмадым,
Бәхеткә чуммадым,
Кичер мине, дустым, кичер син!

*1997*

## ХАСТАХАНӘДӘ

Имеш, җирдә олы эш кырдым:
Ашкындым шул, никтер ашкындым.
Атылдым да кинәт ватылдым —
Хәрәкәтсез яткан таш булдым.

Күп сикердең, диләр, ят инде,
Хастаханә сиңа хас инде.
Ялгыз песнәк тәрәз артында —
Әнә шуңа күзең ат инде.

Тәрәзәне көзге яңгыр юа,
Су түгел ул, ага яшь тулып.
Стеналар буйлап соры шәүлә
Үрли йөрәгемә ашкынып.

Хастаханә бакчасына нигә
Көтмәгәндә кара төн килде?
«Син кирәксең миңа, син бар!» — диеп,
Йөрәккәем шулчак җилкенде.

Юкка чыкты кинәт караңгылык,
Сыешмый бу минем акылга:
Күзләремне ачсам, син торасың
Яңгыр юган тәрәз артында.

*1997*

**ТЕЛӘК**

Күзгә карап мактаганчы,
Кыйна мине — ару булыр.
Ә мактасаң үзем юкта —
Рухыма бер дару булыр.

*1999*

*** * ***

Ак кар, җиргә кунганчы,
Була, диләр, җилнеке.
Ә син, җилгә тидермичә,
Булсаң иде минеке.

*2003*

**СӨЙЛӘ СИН АҢА, СӨЙЛӘ...**

Исенә төшермә җиләкнең
Ак чәчәк аткан чагын.
Сөйлә син аңа, кабат сөйлә
Яшьлекнең кайтачагын,
Киләсе язларда тагын
Шау чәчәк атачагын.

Исенә төшермә яңгырның
Кар катыш яуган чагын,
Сөйлә син аңа, кат-кат сөйлә
Гөрләвек булачагын,
Иделгә коячагын,
Ләйсән күк явачагын.

Исенә төшермә гүзәлнең
Үткәнен, балачагын.
Сөйлә син аңа, кат-кат сөйлә
Бәхетен табачагын,
Нәниләр туачагын,
Шәп ана булачагын.

*2002*

**«СЕЗ НИНДИ АКЫЛЛЫ»**

Чибәр хатын белә үз бәясен,
Мактау кирәк түгел бу яктан.
Син чибәр, дип, син матурсың, диеп
Ега алмас беркем аяктан.

Алар көтә бездән башка нәрсә,
Син сылу, дип берүк эндәшмә.
Матурлардан түгел, тапкырлардан,
Акыллыдан алар көнләшә.

Сокландырмак булып чибәрләрне,
Сата күрмә җитмәс акылны.
Әйт аларга читләтмичә генә:
«Их, сез, кызлар, нинди акыллы!»
*1999*

**ЭШЛЕКЛЕ УЛЛАРЫМ**

Язмыйм инде — җитәр инде,
Почталар китәр инде.
Почта саен хатлар көтеп
Гомерләр үтәр инде.
Төрлегез төрле якларда —
Ник хәбәрләр бик сирәк?
Сагынам сез бәгырьләрне —
Инде нишләргә кирәк?
Барыгыз да оныттыгыз,
Киттегезме бик баеп?
Барыгыз да эшлеклеләр —
Үземдәдер шул гаеп.
Язмыйм инде — җитәр инде,
Почталар китәр инде.
Көн тудымы, хәбәр көтеп
Гомерләр үтәр инде.
Язмышлардан узмыш юк шул,
Эштә үтте елларым.
Сагынырсыз — мин булмамын,
Әй, эшлекле улларым...
*1996*

**БАЛАЛАРГА**

Сезнең әле барсы алда —
Кыя-таулар үтәсе бар.
Аргамактай оча хыял —
Максатларга җитәсе бар.

Сезнең кулга кала, балам,
Сибелгәнне җыяр заман.
Югалтканны табар заман,
Үз урынына куяр заман.
*1996*

**ИКЕ КУЛЫМ, ӨЧ УЛЫМ**

Үчтүк, үчтүк, өч улым…
Алыйм дисәм кулыма,
Нишләсәм дә, җитми кул
Иң кечкенә улыма.

Их, улларым, их, улым,
Ике генә бит кулым.
Ничек барыгызны да
Кулга алыйм соң, улым?

Их, улларым, их, улым,

Булса иде өч кулым,
Алыр идем хәзер үк
Өч кулыма өч улым.

Кече улым: «Миңа, — ди, —
Ярый, әткәй, муен да.
Айдар белән Айваз, — ди, —
Утырсыннар кулыңда».

«Сизми калып, егылып
Төшмәссеңме, — дим, — улым.
Сине тотып калырга
Юк бит өченче кулым».

«Төшмәм, төшмәм, әтием,
Нык утырам муеңда.
Бер утыргач, бәлки әле
Төшмәм гомер буена».

*1999*

* * *

Оясында ни булса,
Очканында шул булыр.
Әнисе күк, тәм эзләп,
Черек ботакка куныр.

Тотар булсаң очар кош,
Оясына син кара.
Оясында ни булса,
Очканында шул булыр.

*1999*

* * *

Аек акыл, тыныч йөрәгемнең
Ялгышмасын инде мин беләм.
Бер мизгелгә шулай тып-тын калып,
Гомерем юлын күздән кичерәм.

Йокы алмый мине төннәремдә,
Иң салкын бер мизгел җитмичә.
Шул мизгелдә кайнар сулышларым
Көмеш чыклар булып төшмичә.

*1997*

## ЙӨРМӘ, ҮЛЕМ, МОНДА...

*Айнурга*

Бөтен өметләрем син идең бит,
Бары синең өчен яшәдем.
Гомерең бүген кыл өстендә менә —
Нишләдең син, улым, нишләдең?..

Гомерең бүген синең кыл өстендә,
Сулышларың инде кысылган.
Йөрәккәең, туктыйм-туктыйм диеп,
Яздырган шул инде һушыңнан...

Китмә инде, ялгыз итмә мине,
Мәгънәсе юк синсез дөньяның.
Син яшәсәң генә бәхетле мин,
Язмыш, нигә болай уйнадың?

Теләгемне Тәңре ишеттеме:
Йомык күзләр шулчак ачылды.
Кайгыларым кинәт басылды да,
Куанычтан йөрәк шашынды.
..................
Кочагыңны, бәхет, ач инде,
Йөрмә монда, үлем, кач инде!

*1996*

**ӘБИЛӘР ЧУАГЫ**

Сары көзнең, кыштан качып,
Җәйдә буталган чагы.
Кырпы үлән чабыйм диеп,
Алдым кулыма чалгы.

Ак пәрәвезләр узыша,
Ап-ак нурда коенып.
Ник соң әле калды бу көн
Күңелемә уелып?

Алтын көзем, кыштан куркып,
Кайткан икән җаенә.
Сары яфрак соңгы кабат
Талпына җәй җилендә.

Иртәгә үзе төшәр ул —
Син аны бүген өзмә!
Син аны бүген өзмә!

*1998*

**АЕРМА НАЗЛАРЫҢНАН**

*(Җыр)*

Гөлем, диеп дәшә күбәләгең, —
Шактый әле кояш баерга.
Язларыбыз инде үтте, диеп,
Назларыңнан мине аерма.

Игътибарым җитеп бетмәсә дә,
Канатымны минем каерма.
Кырыслыгым кайчак әрнетсә дә,
Назларыңнан берүк аерма.

Син бәхетем минем, куанычым,
Язлар үтте, диеп кайгырма.
Шактый әле кояш баерга,
Назларыңнан гына аерма...

*1997*

*** * ***

Мине белгән, хөрмәт иткән җаннар
Кими бара фани дөньяда.
Ә яшьләрнең үз кайгысы кайгы, —

Күнә барам инде моңа да.

Көч-егәрең бетсә, кырын карый
Гомер иткән якын кешең дә.
Җан җылысы бирми башлый хәтта
Иң яраткан шөгыль, эшең дә.

Көч-егәрең тәмам бетеп куйса,
Кемгә кала синең кирәгең?
Кеше кулларына калдырмыйча
Тына күр син, тугры йөрәгем...
*1998*

## ОЗАТЫРГА КИЛМИ КАЛМА...

Вакыт дигән тар булса да дөньялыкта,
Соңгы юлга озатырга килми калма.
Килми калсаң, керермен дә төшләреңә,
Уяныpсың мине уйлап иртә таңда.

Үлеләрдән шикләнәм, дип, берүк, яме,
Соңгы юлга озатырга килми калма.
Рухым минем исәннәргә зыян салмас,
Тик тереләр куркыныч ул, шуны аңла.

Таш атканга, дөньялыкта аш аттым мин,
Үч тотмадым беркемгә дә, шуны аңла.
Юк-бар нәрсә саклап күңелеңдә миңа,
Соңгы юлга озатырга килми калма.

Йөзләремә бер моңаеп карыйм дисәң,
Соңгы юлга озатырга килми калма.
Барыбыз да кунак кына бу дөньяда,
Чират җитсә, күңелеңә авыр алма,
Ә шулай да озатырга килми калма.
*1998*

## СОҢГЫ КҮБӘЛӘК БУЛЫП

Көзләр килде сиңа никтер иртә —
Җилләр яфракларны куып йөртә.
Яфрак ята янып тезләреңдә.
Нәрсә бардыр, белмим, йөрәгеңдә...
Язлар нуры һаман күзләремдә.

Бакчаң инде синең бушап калган,
Тик арчылма, иркәм, яфраклардан.
Кышлар карсыз килеп, җилләр купса,
Җилләр бөтерелеп мине куса —
Яфрак саклар сине суыклардан.

Чәчәкләрнең хуш исләрен сөйсәң,
Һәм бакчаңа язлар килсен дисәң,
Кояш булып керәм күзләреңә,
Күбәләктәй кунам миңнәреңә,
Урын калса миңа йөрәгеңдә.

## Көзге кояш тауга сыенганда

* * *

Көзнең сары җырларын
Җилләр чәчә дөньяга.
Бер карасаң, яфраклар,
Бер карасаң, кар ява...
Ә наратлар тын гына
Җәйне саклый урманда.
Яшел нарат биленә
Сары җилләр урала,
Сары җилләр урала.

*1961*

### ТИК БЕР СӘГАТЬКӘ

— Күреп кенә чыгыйм дигән идем,
Әнкәй, сине, туган авылны...
Мине күргәч, күзләреңдә никтер
Энҗе бөртекләре чагылды.
Нәрсә булды, әнкәй, бүген сиңа,
Нигә болай артык уйчан син?!
Үтешли, тик бер сәгатькә кердем,
Уйларыңны куеп торсаңчы!
— Уйларымны әйтми кала алмыйм,
Соңарырмын, улым, юкса мин...

...Ачылып китте әнкәй...
Көн дә үтте,
Керфек какмый үтте төнем дә.
Гомер җитмәс иде уй-хисләрен
Кабат аның сөйләп бирергә.

### ӘНИЕМӘ

Бик сагынып кайттым сине, әнкәй,
Кулларыңны кыстым зарыгып.
Синнән күчкән кайнар хисләр миндә
Ялкын булып китте кабынып.

Катырак та кыстым бугай кулың,
Мөлдерәмә тулды күзләрең.
Мөлдерәмә тулы күзләреңдә
Әйтелмәгән үпкә сүзләрең...

Сагынып ла кайттым, әнкәй, сине,
Ничек әле синең хәлкәең?
Дөнья куып үтеп китә вакыт,
Кичер инде безне, әнкәем!

Сызланса да тәнең, сыкранса да,
«Әйбәт, улым!» диеп дәшәсең.
Синең сабырлыкка кем генә соң
Сокланмыйча түзеп яшәсен?!

Бик сагынып кайттым сине, әнкәй,
Күкрәгемә кыстым зарыгып.

Синнән күчкән хисләр йөрәгемдә
Ялкын булып китте кабынып.

...Бик зарыгып килдем сиңа тагын,
Ничек әле синең хәлкәең?
Тын бүлмәдә иңри кайтавазым:
—Кичер мине, кичер, әнкәем!..

**АЛМАЧУАР КАБЕРЕ ЯНЫНДА**

*Әткәм истәлегенә*

Беркайчан да җилләр тынмый монда,
Кыңгыраулар чайкый башкаен.
Синең дә бар иде кырлар буйлап
Башың чайкап чапкан чакларың.

Кешнәсәң бер үзән яңгыратып,
Кирәк түгел иде берни дә.
Чаба идең җилдәй, безне алып,
Килгән кебек җиргә мәңгегә.

Их, ул көннәр,
Ерак калган көннәр...
Кайтарыгыз, еллар, аларны!
Юк, кайтмыйлар,
Усал еллар бары
Ерагайта бара араны.

Алмачуар!
Мәңге күз алдымда
Шул самими сабый чакларым.
Җилкендереп, зәңгәр кыңгыраулар
Бертуктаусыз чайкый башларын...

Бик сагындым сине, Алмачуар!..

**АНА СҮЗЕ**

Тынлык...
Моңсу тынлык.
Ялгыз ана түшәк өстендә.
Яшәү билгеләре
Сулып бара
Инде төсендә...
Ике нәрсә көтә:
Өзгәләнә
Ана күңеле...
Берсе — улы аның,
Икенчесе — картлык үлеме.
«...Улым!
Бик күп еллар,
Кайтыр, диеп,
Көттем үзеңне.
Сине күрми
Йома алмыйм
Менә күземне.
Кайт...
Барысын кичерәм...

Йомшак бит ул
Анаң күңеле.
Сине күреп,
Тыныч...
Каршылыйсы иде үлемне...»
Юк, ишетмәде бала,
Һәм күрмәде
Анасының
Нурлы күзләрен...
Стеналар...
Бары стеналар йотты
Карт ананың
Соңгы сүзләрен:
«Мин кичергән,
Мин күргәннәр
Сабак булсын
Һәрбер анага:
Как сәкенең
Кагын татытмыйча,
Мендәр бирмә икән
Балага!..»

## МАРСКА

Пычрак таплар бетмәс бу дөньяда,
Пакьли алмас беркем бу илне.
Хет җаныбыз чистарынсын дисәк,
Суз, булмаса, моңлы бер көйне.

## СОҢГЫ МИЗГЕЛ

Ник әле син шау чәчәктә бүген?
Сизмисеңме кышлар җиткәнен?
Иртәгесен шушы бакчада ук
Белмисеңмениләр көткәнен?

Бал кортлары инде күптән поскан,
Кояшы да сүрән, бик сүрән.
Ә шулай да син бит, алмагачым,
Бик канәгать шушы бер көннән.

Гомеренең соңгы мизгелен ул
Аклык белән шулай каплады.
Язлар килде... Алмагачым гына
Башка инде чәчәк атмады.

Ул ел кышлар гаҗәп суык килде...
*1997*

## БЕЗНЕҢ ГОМЕР

Нинди озын безнең бу гомер, —
Күпме җирләр күреп өлгердем.
Елга тиңдер туган һәр көне —
Кайчан җитәр икән унҗидем?!

Кыска да соң безнең бу гомер, —
Эшләнмәгән әле күп эшем.
Аңламыйча менә шуны да
Чабып килә инде җитмешем.

*1997*

*** * ***

Көзге Кояш, соңгы нурын сирпеп,
Сыенганда таулар артына,
Белмим үзем, күңелем никтер
Шул тауларга таба тартыла.

Баксам кайчак шул тауларга кабат,
Нурсыз таугa Кояш охшаган:
Әллә якынлаша баешларым,
Әллә күңелем нурга сусаган?!

*1996*

## СОҢАРМЫЙК

Бер чыга да кояш, бер бата...

*Р.Әхмәтҗанов*

«Бер чыга да кояш, бер бата...»
Бер киткәчтен Җиргә кем кайта?
Кайта...
Кайта да ул, күңелемне
«Җан яктысы» белән юата,
Кайта да ул шаулы мәйданнарга,
Үзе белән сине ияртә.
Мәңге сынмас көчле рухы белән
Яңа сынауларга өйрәтә.
Күңелем аның белән бергә,
Ә күзләрем никтер яшьләнгән.
Җылы сүзем әйтелмичә калган,
Ничек инде шулай яшәлгән?
Туң йөрәкмен, дисәм, алай түгел,
Игътибарсыз бит без, ваемсыз.
Бүлешсәк соң нәрсә булыр иде
Һәр татарның шатлык-кайгысын?..
Уңышларын күреп сөенешсәк,
Борчуларын тоеп бүлешсәк,
Башларыбыз күккә тияр иде,
Очрашканда кочып күрешсәк.
Түләнмәгән бурыч кебек болар
Киткәннәргә инде арадан.
Кем яшәүдән китә, кемдер кайта,
Өзеләләр шулай аралар.
Ник соңардым сүзем әйтергә дип,
Сызланмасын иде яралар.

*1997*

## КЕМНӘР КИЛӘ?

Тик гамьсезгә нәрсә аңа —
Килгән ни дә киткән ни...

*Ф.Сафин*

Иң яраткан, күңел тарткан дуслар,
Ник китәсез Җирдән бик иртә?

Сизенде шул күңелем, сизенде —
Тәңребезме алдан сиздертә,
Язмышлармы шулай илертә?

Әйтелмәгән күпме җылы сүзләр,
Җырланмаган җырлар калды ла...
Күпме хыял, күпме бөреләр
Ачылмыйча гына яндылар —
Җимеш бирә алмый калдылар.

Янар җаннар иртә китә, диләр,
Халык әйтсә инде, хак әйтә.
Сезнең эздән гамьсез җаннар килә,
Күңелемне шунсы сагайта —
Битарафлар безне вагайта.

*1997*

## ЗАМАН БАЗАРЫНДА

Йөрим адәм базарында...
Кемдер сата мускул көчен,
Кемдер итләч йомшак тәнен,
Кемдер — җырын, кара эшен —
Тешләремә тими тешем...
Ай-яй салкын!..
Җиле әче, коя яңгыр,
Янса йөрәгең, әйдә яндыр,
Янарлыгы әле бардыр.
Юкса сиңа тик бер юл калыр —
Сулышыңны «чихут» алыр.
Ай-яй салкын!..
Туңып беткән бабай белән
Эткәенә аның ни калган?
Икесе дә ач һәм ялангач —
Как сөяк тә бары ми калган.
Соңгы теләкләрен-өметләрен
Муен тактасына ул язган:
«Үзем бик карт, эт аяксыз,
Бет-тем, диеп тибә йөрәгем.
Фәрештәләр качкан бу илдә
Кемгә бар соң минем кирәгем?
Бет-тем, диеп тибә йөрәгем».
Ай-яй салкын!..
Җиле әче, коя яңгыр,
Бу җаннарны ни соң яшәтә?
Чыкмый икән газиз җан да,
Өмет дигән әле яшәсә,
Өмет әле синдә сүнмәсә...
Ай-яй салкын!..

*1997*

## ҮЗЕМ ИСӘН ЧАКТА...

Әйләнәм дә кайтам шул елларга,
Кукыларга карыйм сокланып,
Әй йөргергә иде юа ашап,
Шәпи сугып, көн да шукланып.

Ачлы-туклы ул елларны бүген

Теләсәң дә булмый кайтарып.
Әмма шулай яшьлегемә кайтып,
Көн дә йөрим гүя шатланып.

Әйләнәм дә кайтам шул елларга, —
Өмет очкыннарым сүнмәсен.
Ул еллардан күчкән хыялларым
Үзем исән чакта үлмәсен!
Үзем исән чакта сүнмәсен!

*2002*

## НЫГРАК КАК, ҖИЛКӘЙ, ИҢНӘРЕМНӘН!..

Ныграк как, җилкәй, иңнәремнән:
Мин күнеккән синең шавыңа.
Бигрәк яшьли бөтереп керттең мине
Чал канатлы дулкын тавына.

Үкерә-үкерә ташланды ул өскә,
Яшь буыным, дидем, түз генә...
Мин татыган тозлы күбекләрнең
Тәмен оныталмам тиз генә...

Тормыш җиңел түгеллеген беләм,
Авырлыклар килсә, мин көчле.
Иң беренче сынауларда, җилкәй,
Үзең бирдең миңа бу көчне.

Ныграк как, җилкәй, иңнәремнән!..

## ОЗЫН КУАК ҺАМАН ЮКСЫНА

*Әткәем истәлегенә*

Икәү яккан учак урыннарын
Табалмадым, күпме эзләдем.
Ник эзләдем? Озын Куакта соң
Аз калдымы синең эзләрең?

Мин киттем дә, оныттылар, диеп,
Берүк, әткәй, ялгыш уйлама.
Эзләреңә ятып тыңлыйм җирне —
Озын Куак һаман моңлана...

Ул моңда бар синең йомшак тавыш,
Син кайраган чалгы моңы бар.
Җирәнкәең кешнәве дә таныш,
Арыш шавы, кошлар җыры бар...

Күренәсең сыман һәрнәрсәдә:
Ак чәчәкләр үскән эзеңә;
Арышларның әллә үзе булып
Кайттыңмы син туган җиреңә?

Җанланасың сыман һәрнәрсәдә:
Таныйм сине — күрен, күренмә...
Табигатьнең үлмәс җаны булып
Син яшисең җирем, күгемдә,
Бүген дә!..

* * *

Болар көлә...
Мин елыймын...
Килүемә фани дөньяга.
Ник тудырдың инде, и Ана?!
Сөенгәннәр...
Алар өчен гүя мин җимеш.
Бу дөньяның таш арбасын
Тартышырга килгән мин, имеш!
...................
Болар елый...
Мин көләмен...
Китүемә фани дөньядан.
Ә шулай да
Җирдә калган
Балаларга карап уйланам:
Теләсәм дә юатырга сезне,
Килми инде хәзер хәлемнән. —
Җаным инде аеры тәнемнән.
Сез тартачак инде таш арбаны,
Бу дөньяның авыр арбасын.
Өлешемә тигән көмешем, дип,
Киләчәккә шулай барасы.
Әй, балалар, шулай барасы...

*1996*

## ЮКСЫНУ

Юксындыра...
Юксындыра Әреш чишмәләрем,
Шул чишмәдә сулар эчкәннәрем.
Бер кайгысыз,
Бер хәсрәтсез килеш,
Апайларым, үскәннәрем белән
Тәгәрәшеп бергә үскәннәрем.
Сагындыра...
Юксындыра...
Әткәемнең җылы карашлары,
Әнкәемнең тәмле каз ашлары.
Кайчан үсеп җитәрбез, дип, без дә,
Бармакларны бөгә-бөгә көн дә,
Каршы алган чаклар кояшларны.
Сагындыра...

*2000*

## КҮЗКӘЙЛӘРЕҺАМАН ТӘРӘЗӘДӘ...

*Бер-бер артлы ике улын югалткан*
*Гөлҗәннәт апага*

Күзкәйләре һаман тәрәзәдә —
Улларының кайту көне бит.
Елмаешып кайтып керерләр дип
Көтә ана, көтә сөенеп.

Каршы алып шулай һәм озатып
Күпме гомер җирдә яшәлгән.
Тик нигәдер көне чытык бүген,
Тәрәзәләр никтер яшьләнгән.

Түбәләрне кагып җилләр дулый,
Яфракларны куып ул йөртә.
Ян ишеккә шыксыз бәрелә дә,
Гүя сиңа хәбәр белгертә.

Тәрәзәдән күзен алмый ана —
Төн җиткәнче керфек какмады.
Ә җилләр соң әллә сизенгәннәр —
Сөйгән улы ник соң кайтмады?

Төн карасын ярып хәбәр килде,
Үкси-үкси җилләр елады.
Үткән яралар да төзәлмәгән,
Ана күңеле ничек чыдады?
Ана күңеле ничек чыдады?..

*1997*

## ЯЗГЫ МОҢ

*Әнием кабере янында*

Язгы җил соң ник моңланып
Тирбәтә кылганнарны?
Килгәнме бире юксынып
Бу кышта тынганнарны —
Суыкта сулганнарны?

Язгы җилкәй сыйпап узды —
Нәкъ әнкәем куллары.
Ул куллардан йомшаграк
Башка куллар булмады —
Күңелем наздан туймады.

Их, җилләр белән еракка,
Бик ерак очсаң иде.
Сине шул җирдә очратып,
Еласам, кочсам иде,
Еласам, кочсам иде.

*1995*

*** * ***

Ера-ера зәгыйфь тамырларны,
Кайнар каным кая ашкына?
Тәнемдәге нечкә капиллярлар
Ярылалар түзми басымга.

Тамырларның юлы тарайганда
Тибә йөрәк, тибә көчлерәк.
Китәр өчен шундый уңай вакыт...
Тик, китәсе килми, ди йөрәк.

*1999*

## МИН КИЛЕРМЕН ӘЛЕ КАБАТ

Канат җәеп очып барам кебек
Фани дөнья аша чиксез күккә:
Чиксезлеккә, кабат Мәңгелеккә.

Еллар үткәч, бер килермен әле
Аккош булып шушы үзәнлеккә,
Гашыйк булып сезнең гүзәллеккә.

Бер генә кат килмәс әле җаным
Кунак булып шушы җирләргә,
Дөнья куып, бәхет эзләргә.
Чәүкә булып килсә әгәр җаным,
Ашыкмагыз мине тиргәргә —
Чәүкәләр дә кирәк илләргә!

Канат җәеп китеп барам кебек
Фани дөнья аша Мәңгелеккә.
Мәңгелеккә, чиксез зәңгәр күккә.
Зәңгәр күкләр аша килермен күк
Аккош булып шушы үзәнлеккә,
Гашыйк булып сезнең гүзәллеккә.

*1999*

## АЛ ТАҢНАРДА

*Хәниягә*

Без барда да ата бу таңнар,
Без киткәч тә атар бу таңнар.
Сихри таңның алсу нурларында
Коенырлар әле саф җаннар.

Син елмаеп киттең арабыздан,
Гөнаһысыз киттең дөньядан.
Зәңгәр күзләреңә гүя багып
Уйланам да һаман уйланам.

Үзең өчен түгел, кеше өчен,
Меңнәр өчен җирдә яшәдең.
Көтмәгәндә безнең җанны айкап,
Соңгы тапкыр кинәт яшьнәдең.

Авыруларың сагына сине бүген,
Сагыналар якын дусларың.
Яңа елны, сине көтеп зарыгып,
Мөлдерәп тора яшьле тостларым.

Син барда да атты ал таңым,
Син киткәч тә атты ул таңым.
Алсу таңның сихри нурларында
Коена кебек синең саф җаның.

*2001*

## КАЙДА СОҢ СИН?

Кайда соң син?
Кабер ташың кая куйыйм?
Кайларга соң ятып елыйм?
Анда? Монда?
Күмелмәгән мәет кебек,
 ничә еллар
Мәңге сүнмәс нәфрәт көйри
Минем җанда.

Мөмкин түгел синең өчен
үч алу да:
Күптән инде китеп барды
Ул да, бу да...
Бернәрсә дә кылып булмый,
Күпме уйла...
Ә күзләрем тик һаман да
Киткән юлда...

*1991*

## АРА-ТИРӘ ЧЕМЕТКӘЛӘП

### САЗ СУЫ

Бер сазлыкка ташу суы
Кереп калган,
Һәм шунда яткан бүрәнәгә
Аваз салган:
— Миндә гайрәт, миндә көч,
Синең кебек көчсезләрне
Ил гиздерү минем эш.
Шапырынганын тыңлап торгач,
Түзалмаган бүрәнә:
— Дускай, мәйтәм,
Тынчыгач син
Онытмансың чамаңны да.
Кузгату юк сиңа хәзер
Мине түгел, саламны да.

### КАРГАЛАР ТЕАТРЫНДА

— Кызганыч, — диде Карга
Былбылга, —
Тавышың килми җырчы булырга.
Кабул итмибез моңга сайларны,
Театр ала
Тик каргадайларны.

### БУНТАРЬ СЕБЕРКЕ

Ачылмас булды ишекләр —
Буран һаман себерде.
Мондый хәлгә хәйран калып,
Баш күтәрде Себерке.

Йортлар идарәсенә ул
Куйды бик катгый таләп:
«Кар яумасын, тынсын буран —
Сезгә минем шул теләк!»

Идарә соң ни эшләсен
Зур кала урамында?
Ничек ул карны туктатсын,
Бассын йә буранын да?

Беркөн шулай урамнарда
Тынып калды бураннар...

Чүп-чарларны себерде җил,
Кояш ялмады карны.
Эшсез калам, дип, Себерке
Таләбен кире алды.

Ә язга ерак иде...

*1991*

## КИЛЕШҮ

— Киңәшик әле, — диде Төлке Куянга, —
Мәсәлән, нигә сиңа озын аяк?..
Юләрләнеп, нигә миңа сине куарга?
Моннан соң үч тотуны без ташлыйк.
Урман киң бит, әйдә, чык ояңнан,
Тыныч, тату яши башлыйк.
— Мин каршы түгел, — диде Куян, —
Моның өчен нишләргә соң, Төлке туган?
— Мин, — диде Төлке, — татулыкка кул куям.
Әйдә кыскарт син аякларыңны, Куян.
— Ә үзең, Төлке дус, үзең уйлыйсың нишләргә?
— Миңа калса, әзермен төсемне үзгәртергә:
Җәен — соры, кышын ак төскә керергә!

## ҮТТЕ ШУЛ ЗАМАНАЛАР

*(Җыр)*

Елмайдылар чибәр кызлар,
Бер-берләреннән көнләп...
Кызлар күрсәм, искә төшә
Нәчәлник булган көннәр.
Үтте шул заманалар,
Кайтмаслар инде алар.
Йолдызымның истән чыкмый
Серле елмаюлары.
Шуннан гына булды инде
Постымнан алулары.
Бар иде заманалар,
Үтте шул заманалар.
Эштә — Йолдыз, өйдә Былбыл
Күрә иде күңелем.
Йолдыз сүнде, Былбыл очты,
Калдым хәзер берүзем.
Бар иде заманалар,
Үтте шул инде алар.
«Йолдыз балкыр, Былбыл кайтыр», —
Дип, мине юаталар.
Юаталар, уйлаталар,
Төрле шик уяталар.
Үтте шул заманалар,
Кайтмаслар инде алар.

## АЮ

Урман.
Ай нур сибә күктән.
Куян мактый Ай нурын.
Бу күренеш ни өчендер

Кәефен боза Аюның:
— Ник мактыйлар гел Айны?
Ник күрмиләр Аюны?
................
Дөм караңгы итмәк булып
Урман һәм кыр якларын,
Сузылып җиргә ята да
Күтәрә аякларын...
Дөрес, Аю өчен Ай каплана,
Башкалар өчен ул күктә кала.

## КИҢӘШЧЕ ТАВЫК

Әйтте бервакыт Тавык Тургайга:
— Өйрәнмәгәнсең әле очарга.
Болай килешми синең күк кошка,
Күз төшергәлә безнең очышка.

## ЮКӘДӘ ИКӘН ЧИКЛӘВЕК

Гомер буе тик ырлашып яшәгәннәр
Бүген нигә елмаешып торалар тост?
Күзәткәнең булса, беләсеңдер:
Бүре күргәч, этләр дә бит булалар дус...

## БУШ КАПЧЫК

Баштарак ул сам да, зам да,
Замның замы да булды.
Йөз урында булды ул,
Йөз урыннан шылды ул...
Кайберәүләр сорау бирә:
— Ник куыла, ник торалмый?
— Беләсездер,
Буш капчык бит
Үз урынында утыралмый.

## КЕМГӘ НИЧЕК

— Минем сазда ни кыласың? — диде Сөлек,
Салам сөйрәп килгән Кырмысканы күреп.
— Сазың аша, — ди Кырмыска, — күпер салам.
Бик күпләр бит газап чигә синең саздан.
— Булмаганны сөйләмәле,
Күперсез дә бик шәп әле.

## АЮ ҺӘМ ТӨЛКЕ

Диде Аю:
— Күзгә-башка күренмисең,
Нәрсә булды сиңа, Төлке?
Куяннарны үз итсәң дә,
Безне оныту — бу бит көлке!
Диде Төлке:
— Сездә яшәү яшәүмени —
Шикләнәсез бер дә юкка.
Аягөсте йоклап йөреп,
Басасыз сез гел койрыкка...

*1999*

**КҮРШЕЛӘР**

— Сәлам, күрше!
— О-о, Вәли дус,
Кая юл тоттың болай таң белән?
— Сезгә килдем, юлым уңмасмы дип.
Ферма тулы тирес өемнәрен күргәч,
Килдем сиңа, Гали,
күрше итеп,
Сатлык тирес булмасмы дип.
— Димәк, гәҗит
һәрвакытта сезне мактап
алдаган.
Баксаң, «үрнәк»ләрнең
салам түгел,
тиресе дә калмаган.
Ал! Бирәм бушлай...
тирес бездә җитәрлек,
Хәтта сыер абзарыңны күмеп китәрлек.
— Рәхмәт, күрше!
Беркайчан да игелегең онытмам.
Әҗәткә ашлык бирербез
Быелгы мул уңыштан.

**«ТЫЙНАК» МӨДИР**

Бик тыйнак һәм саф күңелле
Күренде ул һәркемгә:
— Барамы соң?
— Бара! Бара
Мөдир булу Хәкимгә!
Бик тыйнак һәм саф күңелле
Күренде ул һәркемгә.
Еллар үтте...
Хәзер инде
Таю яхшы Хәкимгә.
Саф күңелле Хәкимҗанның
Бар хәзер үз амбары —
Ошатыпмы тыйнаклыгын,
Күчкән казна маллары...

*** * ***

Дусларыма
Дус калырмын гомерем буе.
Син дә, дисәм...
хата икән.
Синдәй дуслар,
Берәр баскыч өскә менсә,
Хәтәр икән,
хәтәр икән.

**КЕМ ГАЕПЛЕ?**

План тулып,

Эшләр җайлы барса,
Үзен мактар,
«Мин», «мин» диеп басым ясар.
Бәла килеп,
Эшләр артка китсә,
Кем гаепле?
Кем булсын — Урынбасар.

**ЙОРТ КӘҖӘСЕНӘ**

Анда керсәң, куалар,
Монда чыксаң, куалар.
Кишер капсаң, сугалар,
Сөт бирмәсәң, суялар.

Бер дә китмичә исең,
Син шуны яшәү дисең:
Имеш, сине яклыйлар,
Бүреләрдән саклыйлар.

Таудагы бабаңнарны,
Аларның балаларын
Юк бүредән саклаучы,
Юк аларны яклаучы.

Күзләр үткен, тәпиләр тиз
Үз-үзләрен яклыйлар...
Берсен берсе саклыйлар,
Ләкин сиңа кайтмыйлар.

Дошманнар күп булса да,
Кайтмый алар нилектән?
Сәбәбе тик бер генә:
Яши алар иректә.

**САНДУГАЧЛАРГА**

Күңелләрне савыктыру өчен
Яратылган кош сез бу җирдә.
Каты күңелләләр арткан саен,
Ник кимисез, дуслар, сез илдә?

**ЧЕБЕНГӘ**

Синең яшәү Җирдә
Гаеп түгел.
Ашка төшсәң, менә
Кайта күңел.

**БАЛ КОРТЫНА**

Синнән игелекле җан иясе
Булды микән ошбу җиһанда?
Кадерең бетте бүген ник бу җирдә,
Бик тырышып нектар җыйсаң да?

Урман-болыннарга әнә ничек
Күчләр сыман корым бөркелә.
Ерак бабаң кайтса монда кире,
Яши алмас иде бер көн дә.

Болын өсләреннән оча-оча,
Үзең күпме сөрем эчәсең!
Чәчәкләргә агу... Кемдер шуннан
Калынайта бара кесәсен.

**САРЫККА**

Башкаеңны иясең дә,
Каян кайтып киләсең?
Ярый әле абзарыңны,
Үз капкаңны беләсең,
Шул капкаңның келәсен
Кайсы якка эләсен.

«Нигә безгә ирек?» — диеп,
Чынлап, ахры, әйтәсең?
Бик ошаса, әйдә яшә,
Башың иеп яшә син.
Бу дөньяда башкача соң
Сарык ничек яшәсен?!

**УРАМ ЭТЛӘРЕНӘ**

Ул да тибә китереп,
Бу да тибә китереп.
Авыртуны басар өчен,
Куйган буласыз өреп.

Ул да бирми ашарга,
Бу да бирми ашарга.
Һаман чүплек актарасыз
Ач тамакны басарга.

Кычкырып та куалар,
Таш атып та куалар.
Урамнарда этләр нигә
Юаш булып туалар?

Эткәйләрем, әй, этләр,
Кая сезнең егетләр?
Нигә болай юашлар сез,
Нигә болай җебекләр?

Ни ашарсыз иртәгә? —
Сезгә карап көенәм.
Пенсия алгач...
Ярый ла, без
Эт түгел дип сөенәм.

**ЧЕБЕН МОНОЛОГЫ**

Табиблар үткәргәчтән консилиум,
Башкаема килде шундый уем:
Кешеләрнең эче китсә — без гаепле,
Теше төшсә йә кителсә — без гаепле.
Ярамый бит чебеннәрне гаепләргә
Үзегездә тау кадәрле гаеп барда...

Ит күп ашап, сизмичә дә картаясыз,
Сөт ярамый, аны эчеп муртаясыз.
Сөякләргә сөяк үри.
Сөт ризыгын күп кулланган
Кул-аягын көчкә сөйри.
Шикәр суын күп суырсаң, диабет була,
Конфет ашап, тора-бара теш коела.
Камыр ашы үзегезне нык симертә,
Майлы әйбер сукырайта, еш кикертә.
Бәрәңгенең дә, беләсездер, бар зыяны,
Күп ашама, тәртипле бул, бул зыялы.
Пенсия дә кирәк булмас бу кадәрле,
Беләсез бит, акча илдә бик кадерле.
Иң яхшысы — ашамаска, ач торырга,
Ачыгырга, гражданнар, ачыгырга!
Хезмәт хакын кисү кирәк күпме кирәк —
Иң мөһиме — таза булыр сезнең йөрәк.
Рәсәйгә дә тияр моның зур файдасы,
Иң мөһиме — калыр безгә — чебеннәргә —
зур калдҗасы.
Шулай булгач, иң яхшысы — ач торырга.
Ачыгырга, гражданнар, ачыгырга!

*1999*

## ОНЫТЫЛМАС АВАЗЛАР

### КУРАЙ ҺӘМ ЕЛКЫТАУ ДИЮЕ

*(Әкият)*

Якты елга ярында,
Карагайлар янында,
Моң таратып, бер Курай
Сакта торган, ди, шулай.
Серле моңнан көч алып,
Дәртле җырдан рухланып,
Карагайлар күптәннән
Үскәннәр дә үскәннәр.
Карагайлар каршында
Җәйрәп яткан саф күлләр.
Күл читендә тирбәлеп
Чәчәк аткан ал гөлләр.
Ул гөлләрне таптарга
Ният итеп килгәннәр —
Моңлы Курай каршында
Көчсез калган барсы да.
Елкытаудан карт Дию
Мең-мең хәйлә эзләгән.
Ул гөлләрне өзәрдәй,
Күлләрендә йөзәрдәй
Дус табарга теләгән.
Ашым үтми, йокы юк, дип,
Курай бирми тынгылык, дип,
Тирә-юньгә шаулаган.
Курай һаман җырлаган,
Кайчагында шомланган.
Җилләр килеп җитсәләр,
Җилбер-җилбер иссәләр,

Яхшы хәбәр әйтсәләр,
Ул шатланып юанган.
Бу якларны күзәтеп,
Комсызланып күз атып,
Ятлар яннан узсалар,
Ул көчлерәк җырлаган...
Әмма бермәлне Курай...
Йоклап киткән, ди, шулай!..
Елкытауда карт Дию
Әй сикергән, куанган.
Баш Мөритен, Гыйфритен,
Сәмрәвен дәшеп алган.
— Ник чакырдым сине, — дигән Дию, —
Беләсеңме шуны, Мөритем?
Курай йоклый бугай, тыңлап кара
Ике колагыңны бер итеп.
Син беләсең Карагайлык җирен,
Сиңа, миңа хөрмәт юк анда.
Һәм булмас та, Курай бөтенесен
Дәртләндереп, җырлап торганда.
Шулай булгач, үзең аңлыйсыңдыр,
Җитте кебек уңай минутлар.
Курай йоклый,
Бер-бер чара күрсәң,
Уянмыйча мәңге ул йоклар!
Колагын салып Курай ягына,
Тыңлады Мөрит бик озак кына.
Шул яктан җилләр килеп җитүгә,
Болай дип әйтте Мөрит Диюгә:
— Урман шаулавын ачык ишеттем,
Курай тавышын анык ишетмим.
Җырламый Курай,
Моңланмый Курай,
Чынлап та, Курай йоклаган бугай.
Елмайды Дию, Мөриткә карап
Һәм әйтте аңа, бармагын янап:
— Күзләрең үткер, колагың сизгер,
Атлан да атка шул якка җилдер!
Ник тынган Курай, бел син сәбәбен.
Әгәр уянса, тапшыр сәламем.
Чакыр Курайны таулар иленә,
Чакыр син аны Дию җиренә.
Макта илемне, арттырып сөйлә,
Илнең хуҗасын тик Дию димә!
Төн карасын ярып, Мөрит
Җилдерде атта:
— Алдыр, малкай, карурманга,
Сер бирмик ятка!
Җылы яңгыр явып үткән,
Шундый саф һава.
Тояктан очкан балчыктан
Таулар ясала.
Көч Мөриттә — Пәһлеванның
Билен сындырыр.
Курай тынса, бар урманын
Җиргә сеңдерер.
Ә Курайны юк итәргә
Вакыт уңайлы.
Элдерә урманга таба
Белеп ул җайны.

Аты җилдән җитез чаба,
Тиңнәр юк аңа.
Айның көмеш нурларында
Ялы чайкала.
Йоклаган инде урман да,
Берни дә белми.
Тынган хәтта куаклар да,
Яфрак селкенми.
Курайның үз гомерендә бер
Килде йоклыйсы.
Һич уянмый, әллә инде
Үлем йокысы?!
Әһә,
Тора икән Курай
Менә кай җирдә!
Бер мизгел
Һәм моңлы Курай
Авачак җиргә.
Мөрит кылычын суырып
Алырга итә.
Нәкъ шул чакта гына Курай
Уянып китә.
Моң тарала тирә-юньгә,
Курайның моңы.
Һәм Мөритнең, хәлсезләнеп, салына кулы.
Нәфрәтле моң, тыңлап торсаң,
Аяктан ега.
Мөрит каушый һәм кылычын
Кынына тыга.
Кулларын ул «хөрмәт белән»
Суза Курайга.
Ләкин Курай, күрешкәнче,
Куша тыңларга:
— Ни эш төште башкаеңа
Җиремдә минем?
Бер-бер хәл булдымы әллә
Илеңдә синең?
Мөрит исә елмая да,
Курайга карап,
Тезеп китә Дию сүзен,
Иренен ялап:
— Мин бик шат бүгенге күрешүгә,
Мин килдем бирегә күршедән.
Үзем мин Елкытау җиреннән,
Шикләнмә яныңа килүемнән.
Бик гүзәл як бит ул Елкытау,
Яшәреп-ямьләнеп балкый тау.
Көннәрдән яктырак төннәре,
Нурланып тирбәлә күлләре.
Күрмәссең кайгылы бер кеше,
Сыйлану — аларның бар эше.
Елкытау шатлыкка күмелгән.
Арыйсың тик уен-көлүдән.
Бездә бит яшәргә бик уңай,
Рәхим ит син безгә, әй, Курай!
Хуҗабыз чакырды, ул көтә,
Урыны булыр, ди, биектә.
— Шикләнмим, — ди Курай, — шулайдыр,
Сез көткән ул башка Курайдыр.
Мин мәңге бу җиргә бәйләнгән,

Жырларга, еларга өйрәнгән.
Күнеккән кайгыдан көләргә —
Дошманны жыр белән җиңәргә.
Шулай дип кайтып әйт хуҗаңа
Һәм җиткер сәламем син аңа.
Капыл гына Мөрит борылды,
Йөзе аның кинәт бозылды.
Борылды да алга юл алды,
Ерактагы таулар артына
Аты белән кереп югалды.
Яуды шулчак күктән вак ташлар —
Тоялардан очкан ак ташлар.
Бер таш тиеп, канатын каергач,
Егылып төште җиргә Карлыгач.
Шунда Курай аның ярасын
Моңы белән юып төзәтте.
Төзәтте дә мондый сүз әйтте:
— Күтәрел, Карлыгач, һавага,
Бул, әйдә, күкләрдә — юлыңда.
Тап булсаң тик берәр бәлагә,
Куркыныч якларга юлыксаң,
Онытма мин барын бу җирдә,
Син минем жырымны көйләп оч,
Җирләргә, күкләргә сөйләп оч:
— Туган якта гына юаныч,
Туган якта гына таяныч,
Туган якта гына куаныч!
Бер-бер хәл булганын сизепме,
Көтте зарыгып Дию Мөритне.
Төрле уйлар килде башына,
Бармакчы да булды каршына.
Нәкъ шул чакта урман ягыннан,
Ут чәчрәтеп ат тоягыннан,
Кайтып килә аның Мөрите,
Акланырмы көткән өмете?
Дию кинәт кырыс төс ала,
Сырт йоннары аның кабара.
Җәһәт кенә атны туктата,
Мөритенә зәһәр сүз ката:
— Күзләреңдә өмет күрмим мин,
Анда барып ниләр белдең син?
Курайга, дим, ниләр сөйләдең?
Үзен дәме әллә күрмәдең?!
— Күрдем, падишаһым, — ди Мөрит, —
Әмма нишли алдым соң күреп?!
Чыгармыйча хәтта тыным да,
Кылычымны алып кыныннан,
Чабыйм дисәм, Курай уянды,
Моң урады бөтен урманны.
Эшкә җигим, мәйтәм, хәйләне,
Тик буш сүзгә хәйләм әйләнде.
Тау күчерер көчем югалды,
Курай каян мондый көч алды?
...Туган ягын бик-бик сагынгач,
Ашыгып оча күктә Карлыгач.
Сайлап алган якын, туры юл,
Көйләп бара Курай жырын ул:
— Туган якта гына юаныч,
Туган якта гына таяныч,
Туган якта гына куаныч.

Елкытауның күген ятлардан
Моңа кадәр Сәмрәү саклаган.
Бүген Сәмрәү берни аңламый,
Канатлары һич тә тыңламый.
Карлыгачка күктә ачык юл,
Оясына җитәр барып ул.
Шуны сизгән Дию — зәһәрле,
Сәмрәү кошны Дию каһәрли:
— Карлыгачны тота алмасаң,
Юк, — ди, — башың исән каласы!
Тыпырчына Сәмрәү җан атып,
Тик буйсынмый аңа канаты.
Мөрит, Дию, Гыйфрит җыелып,
Менәләр дә тауга сыенып,
Ыргыталар аны югары,
Сәмрәү төшә кире егылып.
— Кызганыгыз, — ди ул, — тыңлагыз,
Курай җырын көйли Карлыгач,
Көчсез калдым шуны тыңлагач.
Бар явызлык Курай җирендә,
Кирәк безгә шуны җиңәргә.
Тәкъдим итәм сезгә бер хәйлә.
Курайның күп икән тамыры
Бар икән, ди, агы, карасы;
Бар икән, ди, бик-бик сарысы.
Ул тамыры бик тә нечкә, ди,
Бик тирәнгә үтә, эчкә, ди.
Шул тамыры белән көчле ул,
Ала, ди, тик шуннан көчне ул.
Без тиешбез шуны эзләргә,
Эзләп тапкач, йолкып өзәргә!
Дию: «Рәхмәт сүзеңә, — ди, —
Тик кем бара өзәргә?» — ди.
Тыны чыкмый Мөритнең дә,
Телен йотты Гыйфрите дә.
Җавап бирми һичберәү дә,
Текәлгәннәр Сәмрәүгә.
Сәмрәү җайлап, уйлап кына
Болай сөйләргә тотына:
— Эш чыкмый, — ди, — син барсаң да,
Ул барса да, мин барсам да.
Уяу Курай, ул — мең күзле,
Кайдан да ул күрер безне.
Җибәрик без берәр бөҗәк,
Тик ул бөҗәк булсын зирәк.
Таныш булсын Курайга ул
Тегеләй дә, болай да ул.
Шикләнмәсен аннан Курай,
Кайсы бөҗәк моңа кулай?
— Бар яктан да килмәсә дә, —
Диде Мөрит, — мин, мәсәлән,
Күк күбәләк барыр, димен,
Әйбәт белә Курай илен.
Фикерләрен түгәрәкләп,
Чакырттылар күбәләкне.
Моң агылган якка карап,
Чикләр аша җилпеп канат,
Басар өчен сусауларын,
Эчә-эчә чык суларын,
Елкытауның итәгеннән

Күк күбәләк якынлашып
Килә Курай төбәгенә...
Дошман диеп белмәгәндә,
Күңел күзе күрмәгәндә,
Маңгай күзе нәрсә күрсен?
Күбәләкме? Күбәләк ул
Оча бирсен, үтә бирсен.
Ялга килгән дус шикелле,
Курай янына ук куна:
Табып сары тамырны ул,
Йомыркасын салып куя...
...............
Кеп-кечкенә бер күбәләк
Зур явызлык эшләп китте,
Курайның бар көче бетте.
Йомыркадан кортлар чыгып,
Тамырларны ашадылар —
Үз эшләрен башкардылар.
Сызланды Курай ярадан,
Тынып калды ул яңадан,
Гөлләр сулды урманында,
Комнар купты юлларында...
Карагайлар чайкалдылар,
Күл-елгалар чайпалдылар,
Уклар күкне айкадылар.
Тетри җир, күк калтырый —
Таныш аваз яңгырый күк:
«Егыл, урман, тезеңә чүк!»
Сыкрый урман, авыр сулап,
Дию килә барысын турап.
— Мескен Курай, бирел, — ди ул, —
Калды сиңа иң соңгы юл.
Тынып бара синең җырың,
Сүнеп бара йөрәк җылың.
Калмыйм дисәң сеңеп җиргә,
Киттек, әйдә, безнең илгә!
Очынып чыгып Мөрите,
Җикеренде эре итеп:
— Мине кулсыз калдырганны,
Көч-куэттән яздырганны
Чакырмагыз Елкытауга!
Кая Елкытаулар аңа —
Кылыч барда туракларга!..
Юл бирегез, кисәм башын,
Бүтән җырлап кинәнмәсен!
...............
Дошманнарга үчләнеп,
Үч-нәфрәттән көч алып,
Урман күмелде шауга,
Шауны узып, ярсу моң
Таралды еракларга.
Башы өзек, һаман җырлый,
Җырлый Курай, моңлана:
«Мең яшәгән — бер мизгелдә
Тынар диеп уйлама.
Тынар диеп уйлама!»
Дию тагын шашына:
— Чап, — ди, — кабат, чап шуңа!
Чаба Мөрит калтырап,
Кылыч китә ялтырап.

Курайда бер яра арта,
Моң сибелә яктырак!
Тагын чаба, тагын моң,
Тик көчәя талгын моң!
Тәнен сарды мең яра,
Мең ярасы — мең тишек,
Мең тишектән моң ага,
Дошман өметен кисеп.
Курайның бу моңнары,
Үлемсез бу җырлары
Карлыгачка җитәләр,
Шомлы хәбәр илтәләр.
Ә Карлыгач шунда ук,
Әрәм итми минутын,
Оча Курай янына,
Алып йөрәк җылысын.
Ул Курайның төбенә
Уктай очып төшүгә,
Арындыра чүп-чардан,
Арындыра кортлардан.
Табып сары тамырын,
Ясап «үзле камыр»ын,
Сылап куя ярасын,
Савыкмыйча кара син!..
Шул минуттан Курайга
Өр-яңадан көч иңә.
Куркуыннан карт Дию
Катып кала таш кебек.
Мөрит китә тәгәрәп,
Киселгән бер баш кебек.
Очам, диеп, Сәмрәүнең
Канат җилпүе була,
Карт Диюнең иңенә
Тораташ булып куна.
Бөтенесе шул килеш
Хәрәкәтсез калалар,
Кыймылдамас булалар.
Ишетсә дә колаклары
Һәм күрсә дә күзләре,
Салкын таш, ди, үзләре.
Мәңге карап Курайга,
Тыңлап аның моңнарын,
Саныйлар, ди, айларны,
Саныйлар, ди, елларны.
Нишли, димсез, Курайны? —
Хәле аның уңайлы:
Үсеп, җырлап торалар
Янында яшь курайлар...

**ОНЫТЫЛМАС АВАЗЛАР**

*(Поэма)*

**Хәтәр аваз**

Кояш миңа җылы нурын коя,
Чәчкәләргә карап елмаям.
Мәңге шулай көлеп-елмаерга
Килгәнмендер кебек дөньяга.
Дөнья әле мине кораб түгел,
Чыбык бишегендә тирбәтә.

«Күчер инде, әби, күләгәгә,
Монда, димен, бигрәк тирләтә».
Телем юк шул әле, аңламый ул,
Никадәрле генә ялварма...
Алай да бар әле шул бер чарам —
Тотынам мин шундук еларга.
Әбкәм мине ишетеп тә ала —
Үзе атлый, үзе сөйләнә:
«Баламның да күңеле сизгән, ахры,
Хәтәр көннәр килде, сөйләмә...»
Нинди хәтәр көннәр килгән тагын,
Бит очлары нигә чыланган?
Мин еладым, әби килсен, диеп,
Ә соң әби нигә елаган?
Уйларыңа җавап дигән кебек,
Болытларга кояш уралды.
Уралды да, йөзен чытып кына,
Бүтән чыкмас кебек югалды.
Сабантуйга киткән этиләр ник
Йөгерешеп кайтып җиттеләр?
Мондый көнне бер дә хәтерләмим,
Ни булган соң, бар да җитдиләр?
«Сугыш! — диде эти, кырыс кына. —
Кирәк бит, әй, шундый чагында!..»
Күзләрендә бүген эткәемнең
Нәфрәт уты гына чагыла.
...Атлар чабып узды урам буйлап,
Карлыгачлар елап очтылар.
Иртәгесен абыйларым мине:
«Хуш, энем!» — дип, кат-кат кочтылар.
...Дөнья әле мине кораб түгел,
Чыбык бишегендә тирбәтә.
Тирләп яткан җирдән тәпи атлап
Китәр өчен шулай өйрәтә.
Сугыш!..
Тәүге тапкыр менә шушы аваз
Калды минем кереп күңелгә.
Үткәннәргә сабак,
Киләчәккә набат —
Чыңлый һаман колак төбемдә...

**Аналар авазы**

Ничә көннәр чыбык бишегемдә...
Ишеткән юк ирләр авазын.
Тик кайтаваз булып кайта алар,
Кичергәндә үлем газабын.
Аналарның кунып керфегенә,
Һәр кайтаваз сеңә күңелгә.
Өйрәтә ул читен минутларда
Тешне кысып түзә белергә.
Көн суынды...
Кояш яшердеме
Тылсым тулы серле таягын?
Тупыл башларына тияр-тимәс
Кара болыт ага каядыр.
Ялгыз козгын... Кем китергән аны? —
Әй кычкыра тупыл башында.
Әби күргән, эчтән сөйләнә ул:

«Булса иде тик үз башына...»
Козгын очты кара болыт белән,
Сөйлисен ул сөйләп бетерде.
Аның артыннан ук хат ташучы
Соры конверт безгә китерде.
Ник кычкырдың, әйтче, кара козгын,
Аз идеме әнкәм кайгысы?
Тагын менә олуг яу кырында
Күзен йомган туган абыйсы.
Үксер дигән идем... түзде әнкәй,
Ышанмады бугай хәбәргә.
Аның өчен җилләр еладылар,
Ул җыенды ерак сәфәргә.
Еларга да вакыт тими җирдә,
Орлык кирәк язын чәчәргә.
Җирән бия белән орлык эзләп
Китте әнкәй торып сәхәрдә.
................
Үч иткәндәй, ул ел язлары да
Кинәт кенә килде кырларга.
Ник син, кояш, өреп эреткәндәй,
Су тутырдың кышкы юлларга?
Әнкәй кайтты билдән суга чумып,
Ярты капчык бодай кулында.
Җирән бия, җене өзелгән дә,
Үлеп калган Чаллы юлында.
Чаллы юлы буйлап авылгача
Күпме чакрым кайткач чыланып,
Әнкәй килеп ауды урын-җиргә,
Эчтән сыкрап, тыштан сызланып.
Авыр сулап шулай озак яткач,
Бирешкәндер, дидем, күңелдән.
Ә уянсам, төн карасын ертып,
Фермага ул чыгып йөгергән...
Түзсә түзә бары ана җаны,
Корыч түзми, корыч тутыга.
Чуерташлар түзми, шартлап чатный —
Таш уала, юшкын утыра.
Әҗәл үзе килсен, башын имәс,
Күзләреннән шуны күрәмен.
Кайтавазы фронт кырларының
Чарлый гына анам йөрәген.

* * *

Җилләр алып килде ачы хәбәр,
Җилләр түгел, солдат Минһаҗтин.
Башын тотып, әнкәм катып калды:
«Ирең кайда... белмим», — дигәчтен.
Очраштырган аны нинди язмыш,
Ул әткәмне күргән күрүен.
Сөйләгәндә тик нигәдер Минһаҗ
Тели кебек аның үлемен.
Күзләре дә... нигә андый аның —
Тычкан күргән мәче шикелле.
Ә шулай да әнкәм алдында ул
Күренмәкче була сөйкемле.
Күренмәкче була әүлиядәй,
Күңеле аның, ахры, мутлыкта.
Хуҗа итеп сизә һәрбер җирдә,
Файдаланып ирләр юклыктан.

«Мин уйлап чыгарган уй түгел,
Хакыйкать, нишлисең, хакыйкать,
Гомерең узмасын бушка, дим,
Болыннар әйләнеп кайтыйк, ә?!»
Зәһәрләнеп китте әнкәм йөзе
Мут Минһаҗның мондый сүзеннән.
Белмим, ничек кулы күтәрелде —
Ут күренде солдат күзеннән.
Әнә шулай тәүге тапкыр бу ел
Ишеттем мин ирләр авазын.
Ләкин ирләр авазымы, белмим,
Вакыт бирер моңа җавабын.
...Өй салкынча кебек иде миңа,
Хәзер инде никтер тирләтә.
Иске генә чыбык бишегендә
Дөнья әле һаман тирбәтә.

## Кошлар авазы

Гөрләвекләр акты урам буйлап,
Сыерчыклар кире кайттылар.
Акчарлаклар Низам күле өстендә
Җилфер-җилфер канат кактылар.
Тыныч елдагыча шау-гөр килеп,
Ил сагышын дәртле моң итеп,
Куандылар алар, кайткач илгә,
Мәшәкатьле авыр юл үтеп.
Каурыйлар көйгән ут кырында...
Ә күпмесе үзе янгандыр.
Ә күпме кош туган җирләренә
Кире кайта алмый калгандыр.
Күкләр дә бер, илләр дә бер, диләр,
Күреп торам алай түгелен.
Утлар аша эзләр идеме соң
Кыргый кошлар хәтта үз илен?!
Яна-көя кайтты алар илгә,
Кайтты сагынып матур кошларым.
Алар миңа тәпи китерделәр,
Рәхмәт яусын сезгә, дусларым!
Тәүге тапкыр басып яшь чирәмгә,
Тыңладым мин кошлар тавышын.
Һәм башланды, бишегемнән төшеп,
Дөнья белән тәүге танышу.
Салкын сыман иде башта чирәм,
Хәзер инде никтер җылырак.
Баскан саен җиргә кыюрак мин,
Җылысын тоям аның ныграк.

## Башаклар авазы

Кырларыма чыктым менә мин дә,
Җәй җилләре биттән сөйделәр.
Анам кырларында, дулкынланып,
Тук башаклар башын иделәр.
Әнә алар нинди эре булып,
Нинди куе булып үскәннәр.
Аналарның кайнар тозлы тире
Башакларга, ахры, күчкәннәр.
Ник соң әле, тук башаклар, болай

Башыгызны түбән идегез?
Өлгерергә тизрәк телисездер...
Бик тә көтә сезне илебез.
Уып кара, диләр гүя алар,
Төшәргә бит вакыт уракка?!
Батырларга тәмле икмәк булып
Китәр идек без дә фронтка...
Уып карыйм, тулы бөртекләрдә
Кеше яшәешен күрәмен.
Авызымда тоеп икмәк тәмен,
Үзем елыйм, үзем көләмен...
................ ...
Торган чакта басу почмагында,
Исем китеп уңган игенгә,
Көтмәгәндә генә, кинәт кенә
Китереп типте кемдер билемә.
Чайкалсам да, егылмыйча калдым,
Чыдам тәпи кошлар китергән!
Айнып китсәм, председатель Минһаҗ —
Көчкә басып тора — исергән...
«Шакшы малай, — диде миңа, янап, —
Ник урлыйсың колхоз икмәген?
Яшең җиткән булса, белер идең
Моның өчен башың китәрен!»
Еладым мин, әйе, сабыйларча,
Үкси-үкси кырда еладым.
Нахакка бит... Дөрес булса әгәр,
Җитәр иде, бәлки, чыдамым.
Майҗан апа ишеткән дә мине,
Ни булган, дип, килде йөгереп.
— Шул сабыйга кул сузмасаң, Минһаҗ,
Булмас идеме әллә күңелең?!
Ә Минһаҗга шул сүз җитә калды:
— Урлаучыны, имеш, яклыйсың.
Икмәкнең дә кирәк кадерен белү,
Үз тәнеңне юкса саклыйсың...
Кинәт кенә тайпылды да Минһаҗ,
Кысып алды аны биленнән.
Нәфрәттәнме, куркуданмы шулчак
Сискәнгәндәй булды игеннәр...

**Катнаш авазлар**

Күкрәп үтте яңгыр болытлары,
Пошаманга салып авылны.
Ә игеннәр сөрлектеләр җиргә,
Көтмәделәр алар явымны.
Лобогрейка берәү бар да барын,
Ни майтарыр икән ул гына?
Кырлар карый олы өмет белән
Әниләрнең арык кулына.
Авыл урамнары бушап калды,
Кырга күчте кызлар авазы, —
Икмәк көтә илем җиңү өчен,
Төзү өчен җирдә яңаны.
Аналарның кайнар күз яшеннән
Ныгый барса өмет җиңүгә,
Иген кырларында туккән тире —

Җиңү даулашу ул иленә.
Икенче ай китте хәзер менә,
Әнкәйне юк юньләп күргәнем.
Кайтыр инде диеп көтә-көтә
Күгәргәндәй була күзләрем.
Иртәгесен кояш белән торып,
Кояш белән кырга чаба ул,
Җиңү таңын илгә аз булса да
Якынайтыйм диеп яна ул.
Мәчтүрәттәй генә эштә түгел,
Бәбәе, ди, булыр, әбием.
Минһаҗтиннан була икән, диләр,
Туа калса әгәр нәние.
Бер гөнаһсыз,
Бер гөнаһсыз нәни
Әле белми җиргә туасын.
Бер гөнаһсыз нәни белми әле
Алда әллә ниләр буласын...
Нигә дөнья дөрләп янмый шунда,
Котылгысыз аның туасы.
Тусын... Батырларга алмаш булсын,
Тик Минһаҗга охшап тумасын.
Мәчтүрәттәй, һич тә кайгырма син,
Ана булуың белән горурлан.
Синең каның якынрак аңа —
Китмәс балаң Минһаҗ юлыннан...

**Солдат авазы**

Кырда эшнең уттай кызган чагы,
Календарьда инде октябрь.
Майҗан апа кырга җыенганда,
Кайтып төшмәсенме Уктәбер.
Октябрьгә яшьтәш абый үзе,
Исемен дә шуннан алган ул.
Октябрьдә туган ирек таңын
Саклаганда яраланган ул.
Майҗан апа, картын күреп алгач,
Үзе елый, үзе аптырый.
«Аягың?..» — дип сорамакчы була,
Иреннәре генә калтырый.
Күңелендәген аның аңлагандай,
Солдат кинәт җиргә текәлә:
«Аңла, Майҗан, ярты кеше, диеп
Тимәс булсаң гына теңкәмә,
Калам синең белән гомерлеккә.
Авырлыклар килсә, үртәмә.
Ике кулым әле исән чакта
Йөк булмамын синең җилкәгә».
Яшьле керфек аша күзләрендә
Гүя сүнмәс очкын кабына, —
Майҗан апа, тәүге сөюедәй,
Иңнәренә аның сарыла.
Иңнәренә аның сарыла да,
Бер гаилә янә кабына.
Аксакаллар, тол хатыннар уза
Утлар кичкән солдат янына.
Тик нигәдер Минһаҗ гына менә
Көрәштәш дип килми, күренми.

Авылда бит аңа көндәш артты,
Ничек килсен ди ул иренми...
Уктәбернең кайткан көненнән үк
Кара басты аның күңелен.
Тик уйларын, мәкерләрен генә
Кем дә белми иде әле белүен...
............... ...
Баксаң аңа, көн дә ул кемнеңдер
Көтеп йөри кебек үлемен.

*** * ***

Солдат абый безгә килде менә,
Медальләрен күрсәң — бихисап!
Санап чыгалмадым, шунысы бик җәл,
Белми идем чөнки мин хисап.
Фронт юлларын ул искә алды,
Искитәрлек хәлләр сөйләде.
Авызына баккан килеш аның,
Көннең үткәнен дә сизмәдем.
— Иртәгесен эшкә, — диде аннан, —
Юаткандай гүя әбкәйне.
Саубуллашкан чакта адресын ул
Сорап алды бездән әткәйнең.
Нинди тыйнак, нинди күркәм абый,
Ирләр менә нинди була ул!
Әбиләрдән нәниләргә кадәр
Хөрмәт итә аны шуңадыр.
Авыр минутта да кешеләргә
Олы мәхәббәтен саклаган.
Һәр иртәдә керә елмаеп ул
Һәрбер йортка, һәрбер капкадан...

**Көзге аваз**

Күпме тырышмасын авыл халкы,
Кар төшкәнче урак бетмәде.
Урылмаган бодай кырда калды,
Кар каплады кибән төпләрен.
Дулкынланып ята кар диңгезе,
Көзге суык тәнне куыра.
Киткән кошлар моңы булып кырда
Әче җилләр генә сызгыра.
Шул суыкта урак урды ана,
Кар өстендә сукты ашлыгын.
Җил димәде,
Буран димәде ул,
Сизде бары үзенең хаклыгын.
Сорамады хезмәт хакы да ул,
Фронт өчен җаны фида шул.
Артык тапшырылган һәр пот ашлык
Ун фашистны җиргә ега ул.
Шул чагында әйтсә иде Минһаҗ:
«Булдырдыгыз, рәхмәт, хатыннар!»
Юк шул, йорт саен ул тентү ясап,
Хатыннарның йөрде артыннан.
Әй, Гөлмәрьям апа, ник алдың соң,
Ник алдың син бер уч бодайны?
Минһаҗ күзләренә ялварып соң
Кулай күрдеңмени елауны?

Минһаҗ сүздә — фронт, халык яклы,
Ватан-ана һәрбер сүзендә.
Монысы аның бары форма өчен,
Юкса күпме мәкер үзендә!..
«Эшне зурга сузмыйк», — диде сиңа, —
Һәм үрелде нәфис тәнеңә.
Хаклык яклы Минһаҗ әнә шулай
Керде, Мәрьям, синең хәлеңә...

**Яшьтәшем авазы**

Икмәге дә шундый уңган иде,
Кешеләргә генә тимәде.
Ул көзне дә Минһаҗ беркемгә дә
Бер йөз грамм икмәк бирмәде.
Бар ышаныч бәрәңгедә иде,
Үч иткәндәй, ул да уңмады.
Бәрәңгене зурлап, яшьләр бездә
Менә болай диеп җырлады:
«Башымны да кыралар,
Кашымны да кыралар.
Минһаҗ икмәк бирмәгәч,
Миңа ышанып торалар».
Хәкимҗанның газиз әнкәсен дә
Ник соң әле тотып яптылар?
Чабатасын салып караганда,
Бер уч бодай аннан таптылар.
Ун бала — ун ятим калды хәзер,
Калды өйдә барысы өелеп.
Билгеле инде, Минһаҗ бер тапкыр да
Карамады моңа көенеп.
Булганынча халык ярдәм итте,
Кулдан килгән хәтле булышты.
Туганнары белән исән-имин
Чыгар сыман яшьти бу кышны.
Көннәр инде язга авышып бара,
Яшь кычыткан тиздән чыгар да,
Шуның белән минем күршеләрем
Бу язны да исән чыгарлар...
Әнкәм биргән бәрәңгене алып,
Кердем бүген мин дә аларга.
Бәрәңгене күргәч, Хәкимҗаным
Тотынды бит кинәт еларга.
Күзкәйләре тәмам эчкә баткан,
Ә йөзләре ачтан саргайган.
Ятимнәрнең ни гаебе бар соң?
Кайгы килә нигә, кайлардан?
Өй эчләре тәмам бушап калган,
Стенада тора бер сурәт.
Минем яшьти, шул сурәткә карап,
Елый һаман, елый көчлерәк.
Абыйсының елатасы килми:
Чак-чак кына аңа сукмады...
«Әнә Сталин карап тора!» — дигәч,
Елавыннан яшьти туктады.
Өй эчләре тәмам бушап калган,
Стенада тора бер сурәт.
Авырлыклар күбрәк килгән саен,
Хөрмәтлиләр аны көчлерәк...

**Серле авазлар**

Карлары һәм бураннары белән
Тагын бер кыш сынды мәңгегә.
Соңгы авазлары авыр кышның
Хәтерләрдән китми әле дә.
Хәтерләрдән китми басуларның
Ачылуы кардан язларын.
Көзен калган бөртек исен сизеп,
Очулары кырга казларның.
Шул казлардай, тезелешеп, кызлар,
Карт-карчыклар кырга юнәлде.
Әбкәй генә: «Башак җыяр идем,
Син булмасаң», — диеп сөйләнде.
Күршеләрне күр син, кай арада
Капчык-капчык башак тапканнар.
Көч-хәл белән кайтып килә алар,
Ә үзләре шундый шатланган.
...................
Бодай ярмасыннан пешкән икмәк
Килә иде бик тә ашыйсым.
Әче катык биреп, малайларның
Алдарга, дим, икән кайсысын?
Хәкимҗан дус бөтен бер күмәчне
Күтәреп үк чыккан өеннән.
Гомер буе ипи ашар кебек,
Әй сөенгән үзе, сөенгән!
Катык кирәк түгел, дигән булды,
Бик теләсәң,
Майга алыштырам яртысын.
Әбкәй күрмәгәндә, маен чәлеп,
Бүлеп бирдем мин дә яртысын.
Бүлештек тә, кеше күрмәсен дип
Кереп шылдык бура эченә.
Майлы күмәч монда ашармын дип
Керми иде хәтта төшемә.
Шундый тәмле, җылы иде күмәч,
Ашаганда телең йотмалы.
Сәер генә кемдер кычкырмаса,
Юк иде шул әле тукталу...
Караңгылык басты кинәт җирне,
Әй, күрегез, кояш тотыла!
Ашалмыйча калган майны куеп,
Мин дустыма таба омтылам.
Сыенабыз бер почмакка барып.
Көн уртасы. Ник соң караңгы?
Шушы караңгылык өзәр диеп
Кем уйлаган безнең араны?
Соңгы тапкыр бергә сөйләштек без,
Соңгы тапкыр күрдек кояшны.
Хәкимҗаным, яшьлек дустым, диеп,
Ник кочмадым икән шул чакны?
Яңгырады кабат сәер аваз,
Мондый чакта кирәк өлгерлек.
«Үләт килә!» — дигәч, авыл буйлап
Ике якка торып йөгердек.
Үләт...
Беренче кат ишеттем мин моны,
Аваз түгел, әҗәл иде ул.
Шул бер таңда авыл кызларыннан

Бик күпләрнең гомерен өзде ул.
Кабатлана шул ук сәер аваз:
«Үләт йөри йорттан йортларга.
Бу үләттән, имеш, йортын кеше
Тәкбир әйтеп кенә коткара...»
Сәет бабай әнә сыер җиккән,
Тәкбир әйтеп сөрә йорт янын.
Сәрби әби чыккан, күр, йөгереп:
— Бармы, Сәет, синең хет җаның?
Җаның булса, әйлән безне дә соң!
Күпме гомер тату яшәдек.
Бу үләттән исән калсак мәгәр,
Якын туганнардай яшәриек.
Сәет бабай, тезген бавын тартып,
Күршесенә табан юнәлде.
Ике йортны бергә әйләнеп ул,
Сөреп үтте яшел чирәмне.
................ ...
Ә безнеке һаман сөрелмәгән,
Үләт инде күптән шундадыр.
Әнкәй эштән кайтып җитмиенчә
Керергә мин өйгә кыймадым.

* * *

Көн туды исә, сәер моң агыла,
Моң агыла, тынмый һәр яктан.
(Ялт-йолт карап йөрим үләтне мин,
Кайчан егар диеп аяктан.)

* * *

Сәет бабай да китте мәңгелеккә,
Бары тавышы калды күңелдә.
Йола алмады тәкбир әйтүе дә
Күзенә карап килгән үлемнән.
Кабер казыйлар инде әниләр,
Әниләр киткәч, нишләр нәниләр?
«Ташлап китмәгез без нәниләрне», —
Диләр нәниләр сезгә, әниләр.
Әниләр,
        әниләр,
                әниләр...

* * *

Кайчан гына көлеп кергән иде,
Бүген йомды күзен Хәкимҗан.
Әнкәсенең үле хәбәрен ул
Ишетмичә китте, ятим җан.
Соңгы энесе дә Хәкимҗанның
Иртәгесен йомды күзләрен.
Сары йөзләреннән бу сабыйның
Хәкимҗанны кабат эзләдем...
Шул кичне үк үләт миңа килде,
Тел очларым чыкты кабарып.
Әҗәл белән көн-төн якалашып,
Йөзем калды көлдәй агарып.
Саташтыра мине явыз үләт,
«Ычкынып» ук китәм кайвакыт.
Андый чакта әбкәй, көттермичә,
Укый башлый «ясин» аятен.

Ләкин бирешмәдем, көрәштем мин,
Үзенә бер солдат кебек үк.
Сөте ярдәм итте сөтбикәнең,
Йокладым мин тиргә күмелеп...
Үләт качты миннән,
Сәбәбе шул —
Баллы күмәч азрак эләккән.
Тик беразын гына бүлеп биргән
Дустым Хәкимҗанга зур рәхмәт.

* * *

Хәкимҗан дус — нәни дустым минем,
Бигрәк яшьли киттең шул бездән.
Искә алыр кешең калды җирдә —
Син китмәссең минем күңелдән.
Калырсың син тәүге дустым булып,
Оныта алмам синең исемне.
Оныкларга әле сөйләрмен мин
Синең хакта җылы хисемне.
Укытучы булыр, дия иде
Синең турыда әнкәң, сүз чыкса.
Алтмышынчы елның балалары
Моңсуланыр, дускай, син юкка.
Исән калган булсаң, үзеңне син
Санар идең, бәлки, бәхетле.
Гитлер дигән кара йөрәк безгә
Өеп бирде шулай «бәхет»не.
Агуланган икмәк — үләт бетте,
Ил кайгырткан безнең турыда.
Батырларга алмаш булып үссен,
Сафка бассын, диеп, улы да.
Ил язмышы өчен көрәш барган
Катлаулы һәм авыр ул елда
Кечкенә бер авылны да шулай
Саклаган шул илем уенда...
Кайтардылар безгә җылы кием —
Пуля тишкән бүрек эләкте.
«Ранин булып кайтты абзаң», — диеп
Мактап йөрдем мин дә бүләкне.
Тик син генә,
тик син генә, дускай,
Арабызда безнең булмадың.
Балкып туар таңнар арасыннан
Күренә кебек йөзең нурланып.

**Фронт авазлары**

Көтмәгәндә яңа хәбәр килде,
Ут эченнән язган әтием.
«Көрәштәшне, дусны күмдем, — дигән, —
Авыр моны, авыр әйтүе.
Күпме еллар саклап йөрткән серен
Чиште миңа үлем алдыннан:
«Минһаҗ туры бәндә түгел, — диде, —
Сыз син аны кеше саныннан.
Госпитальдә яткан адашының
Кәгазьләрен алган үзенә.
Теге мәрхүм юлда җанын биргән,

Минһаҗ киткән туган өенә
(Кәгазьләрен алган көенә).
Югыйсә бит үзем күрдем аны,
Пүчтәк иде, пүчтәк ярасы...
Антын тотар, кире килер, дидем,
Кайтып күргәч туган анасын.
Юк, килмәде...
Ниләр кыра икән,
Белсәң иде шуның язмышын.
Баш имиләр микән аксакаллар,
Ил батыры диеп, ялгышып?
Шуны белә алмый китәм, дускай,
Кала шунысы бигрәк аяныч.
Уйларымны сиңа җиткерәмен,
Син каласың җирдә — таяныч».
Күзен йомды шулай көрәштәшем,
Бетми калды әйтер сүзләре.
Уйларына нәфрәт шаһит иде,
Сүзләренә уйчан күзләре.
Бу хакта бит мин дә элегрәк
Шик белдергән идем хатымда.
Тик нигәдер әйтеп язалмадыгыз
Уегызны Минһаҗ хакында».
...Әнкәй кинәт иреннәрен кысты,
Аңладым мин аның күңелен.
Менә нигә Минһаҗ әтиемнең
Көтеп йөргән икән үлемен.
Хат ташучы Зифа апаны ул
Юкка гына якын күрмәгән.
Хатлар... Бик күп хатлар язган әткәй,
Кулга гына ләкин кермәгән.
Зифа апа үләт белән китте,
Башка кеше ташый хатларны.
Хатлар белән булган бу хәлләрне
Күңелемдә озак саклармын.
Уктәбер дә алган шундый ук хат,
Безгә килеп, ул да киңәште.
«Минһаҗны, — ди, — беләм, дуслар, байтак,
Ничек башларга соң көрәшне?»

**Яшенле төн**

*(Күкрәү авазы)*

Ул төн бертуктаусыз яшен яшьнәп,
Яктысыннан йортлар балкыды.
Минһаҗ дусларына нәкъ шул төнне
Файда итте яшен шаукымы.
Нәкъ шул төндә Куак басуында
Яшен сукты ялгыз имәнне.
Нәкъ шул төндә аны кыйнадылар —
Ләкин солдат башын имәде.
Уйнаклашып торды өч-дүрт шәүлә,
Яшәү белән үлем уйнады...
Яшен суккан имән төпләрендә
Төне буе җилләр елады...
................ ...
Төрле хәбәр китте авыл буйлап:
Имеш, Уктәберне яшен суккан.
— Дөрес түгел, кыйнап атканнар.
— Кыйнаучыны, имеш, тапкыннар да

Күптән инде тотып япканнар.
Кем ябылган?
Беркем берни белми.
Җепнең очы никтер буталган.
Әнкәй дә бит никтер китеп барды,
Кайту белән кечке утаудан.
Караңгылык басты тәрәзләрне,
Инде, мәйтәм, әнкәй өйдәдер.
Юк, кайтмаган...
Ике кеше шунда
Эзләп килде аны нигәдер.
Актардылар барлык почмакларны,
Ут юнәлтеп безнең күзләргә.
Кемнәр болар?
Күзләр чагыла уттан,
Күз алдында кара күләгә.
Күз алдында кара күләгә.

*** * ***

Иртәгесен генә кайтты әнкәй,
Күз төпләре нидән кызарган?
Бер абзыйга озак сөйләде ул,
Бушанырга теләп уйлардан.
Абый исә һәрбер сүзен аның
Терки барды калын дәфтәргә.
Яза-яза авыр сулап куйды,
Эшләр охшый монда хәтәргә.
— Сине кем соң эзләп килгән, дисең,
Кемнәр булсын, аның ишләре.
Уктәбернең гомеркәен дә бит
Шулар кулы гына чикләде.

*** * ***

Соңгы юлга ул көн Уктәберне
Озатырга чыкты бар авыл.
Эш сөючән халык диңгезендә
Кораб кебек йөзеп бара ул.
Ил язмышын яклап тынган батыр
Мәңгелеккә шулай барачак.
Көннәр үтәр... пычырагын җирнең
Язгы ләйсән юып алачак.

*** * ***

Йөз ел үтсен, авыл кабат басар
Ул елларның тавышын тыңларга.
Авылдашлар яшәр йөрәкләрдә,
Исемнәре күчәр җырларга.

**Кайтаваз**

Ул еллардан бирле безне инде
Ничә кыш һәм җәйләр аера.
Казан якларыннан кайтышлый мин
Басып торам Чаллы тавында.
Әнкәй нидер күзли, нидер эзли,
Юксынгандай дустын, сердәшен.

Җирән бия үлеп калган чатны
Табалмас ул, күпме эзләсен...
Анда инде яңа кала туган,
Җәелеп ята әнә КамАЗы.
Каршы ала мине балачакның
Мәңге онытылмас авазы.
Бу авазлар күңел төпкелендә
Гомер буе шулай калачак.
Яңа буыннарны уйландырып,
Киләчәккә алып барачак!..

**ЭЧТӘЛЕК**

**Кайту**


Тагын килде язлар… ......................
Курай .............................
«Иделгә таянма, дисең…» ..................
«Салынды сер бирмәс канатлар…» ............
Кайту .............................
«Бар нәрсә тартыла яктыга...» ................
Бик аз калган иде язга да... ..................
Ак вә кара ..........................
«Дулкыннар» циклыннан ..................
Әсир Тургай .........................
«Сулкылдап тибә йөрәгең синең...» .............
«Ирек даулап тынган йөрәгеңне...» .............
«Татар башы күргәннәрне...» .................
Бүленмәс бербөтен ......................
Мөрит ............................
Кара хат ...........................
Кипте нигә күлләрем? .....................
Әй, син, кеше... .......................
Бал да әче... .........................
Кендек ............................
Маңкорт монологы .....................
Яңа коммунарлар .......................
Йомшак җәеп, катыга... ...................
Ю гөнаһың! ..........................
Сак бул, ди ак кышлар... ..................
Бака күле ...........................
Куян елында .........................
«Югары менгән чакларда да...» ...............
Йөрәгеңдә — халкың моңы .................
Рәсәем минем ........................
Вакланма ...........................
Тау бөркете .........................
Мәңге яшь калды .......................
«Өстәлемдә тора кабырчыклар...» .............
Тимер булу гына җитми ...................
Таза Шаһгали ........................
Дума депутаты ........................
Дөнья бетми .........................
Бетсен террор ........................
Исеме хактыр ........................
Логика ............................
Манежда ...........................
Шовинист монологы ......................
Кыяташлар булып... ......................


**Кабынды бер йолдыз...**


«Шагыйрь түгел үзе, әмма гашыйк…» ...........
Кичер! .............................
Сырганаклар сыман ......................
Күзкәйләрең синең — тирән диңгез… ...........
«Баш очында соры болыт…» ................
Туйдан соң… .........................
Киттең син… .........................
«Тылсымлы сүзләрең белән…» ................
Каламда көз .........................
«Көзнең сары җырларын...» .................
Калыр идем ..........................

Яшь шагыйрьләр ........................
Диалектика ...........................
Кабынды бер йолдыз... ....................
Уяттың .............................
Карлыгандай күзләрең ....................
«Нигә, нигә генә әле...» ....................
Көзге тынлык ..........................
Туннель .............................
Юлга чыкканда ........................
«Еракта, еракта...» .......................
Яңгырдан соң ..........................
Әрешемдә минем язмышларым ..............
Майлы Чишмәдә .......................
«Чыгар диңгезебез...» .....................
Җаның бармы, дип сорыйсың... ................
Ике зәңгәр ук .........................
Өзелеп сөйдем сине яшьлегемдә .............
Нинди сусаган идем... .....................
Кем соң җәлләр?.. .......................
Күрше кызы ...........................
Минзәлә күперләре ......................
Соңгы теләгеңә соңгы җавап ................
Хастаханәдә ..........................
Теләк .............................
«Ак кар җиргә кунганчы...» ..................
Сөйлә син аңа, сөйлә... ....................
«Сез нинди акыллы» ......................
Эшлекле улларым .......................
Балаларга ...........................
Ике кулым, өч улым ......................
«Оясында ни булса...» .....................
«Аек акыл, тыныч йөрәгемнең...» ..............
Йөрмә, үлем, монда... .....................
Әбиләр чуагы .........................
Аерма назларыңнан .....................
«Мине белгән...» ........................
Озатырга килми калма... ...................
Соңгы күбәләк булып .....................

**Көзге кояш тауга сыенганда**

«Көзнең сары җырларын…» .................
Тик бер сәгатькә ........................
Әниемә .............................
Алмачуар кабере янында ...................
Ана сүзе ............................
Марска .............................
Соңгы мизгел ..........................
Безнең гомер ..........................
«Көзге Кояш...» .........................
Соңармыйк ...........................
Кемнәр килә? .........................
Заман базарында .......................
Үзем исән чакта... .......................
Ыграк как, җилкәй, иңнәремнән!.. .............
Озын Куак һаман юксына ..................
«Болар көлә...» .........................
Юксыну .............................
Күзкәйләре һаман тәрәзәдә... ................
Язгы моң ............................
«Ера-ера зәгыйфь тамырларны...» .............
Мин килермен әле кабат ...................
Ал таңнарда ..........................
Кайда соң син? ........................

**Ара-тирә чеметкәләп**

Саз суы .............................
Каргалар театрында .....................
Бунтарь Себерке .......................
Килешү .............................
Үтте шул заманалар ......................
Аю ...............................
Киңәшче Тавык .........................
Юкәдә икән чикләвек .....................
Буш капчык ...........................

Кемгә ничек ..........................
Аю һәм Төлке .........................
Күршеләр ............................
«Тыйнак» мөдир ........................
«Дусларыма дус калырмын...» ................
Кем гаепле? ..........................
Йорт кәҗәсенә .........................
Сандугачларга .........................
Чебенгә ............................
Бал кортына ..........................
Сарыкка ............................
Урам этләренә .........................
Чебен монологы ........................

**Онытылмас авазлар**

Курай һәм Елкытау Диюе *(Әкият)* .............
Онытылмас авазлар *(Поэма)* ................

Литературно-художественное издание

**Зыятдинов** Фарсель Сахапович

НАША ЖИЗНЬ

Стихи, сказка, поэма

Казань. ГУП Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Зыятдинов** Фарсель Сәхәп улы

БЕЗНЕҢ ГОМЕР

Шигырьләр, әкият, поэма

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *Г.В.Панкратова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 06.07.2006. Форматы $70x90^{1}/_{32}$.

Офсет кәгазе. «Футурис» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 6,44. Шартлы буяу-оттиск 6,73.
Нәшер-хисап табагы 5,29. Тиражы 1000 д. Заказ З-508.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111.
Казан, Бауман урамы, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/**
**E-mail: tki@books.kazan.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

ААҖ «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.